НЫК НИГЕЗ
Якын арада агач йортларга өстенлек бирүчеләр артып китмәгәе
> 2



КУНАКЧЫЛЛЫК ҮЗӘГЕ
Лаешта төзеләчәк курорт туристлар санын бермә-бер арттырачак
> 5

ҮЗЕБЕЗГӘ КАЙТУ
Әдип, картәтәй, аяклы энциклопедия... Тукай музеенда Нурихан Фәттахны искә алдылар
> 6

БЕРГӘ ҖЫЕЛГАНДА
Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә
> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 159–160 (29126–29127) | Сишәмбе | 31 октябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ИМЕЗЛЕК УРЫНЫНА – КИТАП

НИ ӨЧЕН ӘТИ-ӘНИЛӘР САБЫЙЛАРЫНА БАКЧАДАН УК РЕПЕТИТОР ЯЛЛЫЙ?

Башлангыч сыйныфта укучы гына түгел, бакчага йөрүче сабыйларның әти-әниләре дә репетиторларны ешрак эзли башлаган. «Авито» хезмәте уздырган сораштыру нәтиҗәләре күрсәткәнчә, узган елгы белән чагыштырганда, илдә андыйлар өчтән бер өлешкә арткан. Бу нәрсәгә бәйле?

pinterest.com

«Авито» хезмәтенең «Укыту һәм курслар» юнәлеше җитәкчесе Игорь Санников әйтүенчә, балаларны мәктәпкә әзерләүдәге хезмәтләргә ихтыяҗ арткан. Әти-әниләр бигрәк тә хәтерне яхшырту, матур язу, тиз уку һәм сәләтне үстерүгә бәйле белгечләрне эзли икән. Бу күренеш илнең һәр төбәгендә күзәтелә. Әмма аеруча Хабаровск, Владивосток, Уфа, Мәскәү шәһәрләренә хас. Шул ук вакытта менталь арифметика (күңелдән тиз исәпләү) белән кызыксынучылар 38 процентка кимегән.

Кукмарада логопед булып эшләүче Алена Газизова ике ул үстерә. Күптән түгел 4 яшьлек Тамерланны футболга яздырган. Тик ул ике дәрестән соң, мин бармыйм, дип киреләнгән. Сабый үзенчә туп кына тибәсе дип уйлаган, күрәсең. Тик анда да күнегүләр ясарга, кагыйдәләр өйрәнергә кирәк.

– Әти-әниләрнең күбесе кичке сәгать 5тән соң түгәрәккә чаба. Балаларын мәктәпкә әзерлиселәре бар. Йөртмәсәң, укый алмаслар, дип борчылалар. Әле уку елы башланды гына, инде шактый танышларым репетитор таба алмый интегә, – ди Алена Газизова. – Әнием иҗат үзәгендә эшли. Анда әти-әниләр 3–4 яшьлек сабыйларына кадәр китерә. Әниләре киткәч, балалар идәнгә ята-ята елыйлар, ди. Бу яшьтә бик иртә бит. Баланы үз теләге белән генә йөртергә кирәк, дип саныйм. Мәктәптә өй эшләре күп бирәләр хәзер. Балаларның күбесе үзләре генә эшли алмый. Шуңа күрә әти-әниләргә алдан чарасын күрергә туры килә инде. Бу проблема тәрбияче, укытучының бала белән шөгыльләнергә вакыты калмаудан килеп чыга. Эшләре тавык чүпләп бетермәслек бит. Өстәвенә конкурсларга да әзерләнергә кирәк. Җиңгән очракта, хезмәт хакына баллар өстәлә.

Бөгелмә шәһәренең «Батыр» бакчасы мөдире Альфира Галәветдинова әйтүенчә, әти-әниләр сабыйларын күбрәк мәктәпкә әзерләнү, инглиз теле түгәрәкләренә йөртә. Инглиз теле өчен сигез сәгатькә 500 сум түлиләр. Җыр, бию, спорт түгәрәкләренә исә иҗат үзәкләренә илтәләр.

– Әти-әниләр балалары интернетта, телефонда утырмасын өчен дип тә төрле түгәрәкләргә йөртә. Акчалы әти-әниләр бер-берсен уздырып, хәтта өч-дүрт түгәрәккә йөртергә тырыша. Әмма нәтиҗә юк. Балалар иртәгесен ял итәргә өлгермичә, арып киләләр. Чама хисе булырга тиеш, – ди Альфира Галәветдинова.

Казанда яшәүче Әлфия Хафизова төзелеш фирмасында менеджер булып эшли. Үзе – җиде балага математикадан репетитор да.

– Арада башлангыч сыйныф укучылары да бар. Әти-әниләре балаларының укуда калышуын теләми. Шуңа күрә йөртәләр дә инде, – ди Әлфия. – Югары сыйныф укучылары имтиханга әзерләнер өчен килә. Бакчага йөрүче балаларга да аз-маз өй эше бирә башлаганнар хәзер. Энеләремнән чыгып әйтәм. Шуңа күрә репетиторларга йөртәләр дип уйлыйм.

Әлфиянең бер дәресе – 500 сум, артыгы кирәкми, ди. Гадәттә бәяләр бер сәгать өчен – 1000–2000 сум. «Әти-әниләрнең акчасы бар, әмма балаларына вакыт бүлә алмый икән, нигә репетитор яллмаска? Ул бала белән кем булса да шөгыльләнергә тиеш бит инде», – дигән фикердә ул.

Айлия Хаҗиева быел рус теле сынавыннан 100 балл туплап, Казан федераль университетының юридик факультетына укырга кергән.

– Бакчадан ук репетиторга йөрү начар түгел. Хәзер бит мәктәпкә укый-яза белеп керергә кирәк. Репетитор яллау-яламау укучының белеменнән тора. Әгәр БДИ бирә торган фәнне яхшы белә икән, ул кирәк түгел. Ләкин репетитор имтиханның нечкәлекләрен яхшы белә, укучыга аерым план төзи. Бу яктан сынауларны югары баллга бирү мөмкинлеге күпкә арта. Мин репетиторга йөрмәдем. Шулай да 11 нче сыйныфта онлайн мәктәптә шөгыльләндем. Елга 30 мең сум акча китте. Бу күп түгел дип уйлыйм, – ди Айлия Хаҗиева.

Сәрия МИФТАХОВА

Фикер

Дания ӘХМӘТОВА, педагогика фәннәре докторы:
– Репетиторлык күренеше мәктәпләрнең абруен югалтудан барлыкка килә дип уйлыйм. Сыйныфта 30–40ар бала укый бит хәзер. Укытучының һәр укучыга да игътибары җитми. Ул актив балалар белән эшләүне кулайрак күрә. Шуңа күрә әти-әниләр репетитор эзләргә мәҗбүр. Беренчедән, бу мәктәпнең дөрес эшләмәвенә бәйле, икенчедән, әти-әни баласына аерым ярдәм күрсәтергә тырыша. Акчасы булганы да, булмаганы да репетитор яллый. Базар шартлары дигән булып, кайбер укытучылар үз укучыларына репетиторлык хезмәте күрсәтә. Әхлак ягыннан дөрес нәрсә түгел инде бу.

Ялган юньлегә илтми

Татарстанда «Хәмер» профилактик чарасы үткәрелгән. Эчке эшләр министрлыгы матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, чара нәтиҗәсендә 7 мең литрдан артыграк ялган хәмернең эзенә төшкәннәр.

Быел барлыгы 40 мең литр чамасы спиртлы продукция законсыз әйләнештән алынган инде. Ялган продукция кертүнең өч юлы ябылган. 65 җинаять һәм 708 административ хокук бозу очрагы ачыкланган.

Моннан тыш полиция хезмәткәрләре профилактик чара барышында 4 мең каптан күбрәк контрафакт тәмәкегә тап булганнар. Шулай ук автоинспекторлар 100 тартма ялган хәмер төягән автомобильнең юлына аркылы төшкәннәр.

Саваплы эш

Татарстанда гошер сәдакасы җыю тәмам. Диния нәзарәте матбугат хезмәте хәбәренә караганда, мохтаҗларга барлыгы 826,9 тонна азык-төлек җыелган. Сарман (88 тонна), Балык Бистәсе (60) һәм Балтач (59,2) районнары мөхтәсибәтләре иң күп гошер тапшырган. Шулай ук Арча (58 тонна), Саба (43), Әтнә һәм Чирмешән (40ар тонна), Теләче (35), Чүпрәле (32,3), Буа (30), Зәй һәм Апас (25әр тонна) районнары да бу җәһәттән зур тырышлык күрсәткән.

Мохтаҗларга ярдәм йөзеннән, мәчетләргә яшелчә, җиләк-җимеш кайнатмалары, тозлы кыяр-помидор, бал китергәннәр. Аксубай һәм Сарман районнары фермерлары –ашлык, Лаеш районында он тапшырганнар.

Исегезгә төшерәбез: җыеп алынган уңышның уннан бер өлеше күләмендә мохтаҗларга бирелергә тиешле сәдака бу. Диния нәзарәте акцияне 2017 елдан бирле барлык мөхтәсибәтләрдә үткәреп килә.

Сигез көнгә нәтиҗә

Татарстан фермерлары 8 ярминкә көнендә барлыгы 641,9 миллион сумлык азык-төлек саткан. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы матбугат хезмәте мәгълүматларына караганда, ярминкәләр башланганнан бирле җәмгысы 6241,5 тонна яшелчә, шул исәптән 4 мең тоннадан артыграк бәрәңге, 624,5 тонна ит, 446,8 тонна шикәр комы һәм 423,7 тонна сөт сатканнар.

Исегезгә төшерәбез: республикада көзге ярминкәләр 9 сентябрьдә ачылып, 23 декабрьгә кадәр дәвам итәчәк. Алар һәр шимбә саен Казанның 14 мәйданчыгында, шулай ук Чаллы һәм Яшел Үзән районнарында, Түбән Кама шәһәрендә үткәрелә. Моннан тыш 26 районда төрле көннәрдә әледән-әле уздырылып тора.

Ярминкәдә азык-төлекне кибетләрдәгегә караганда 15 процентка арзанрак бәядән сатып алырга мөмкин.

Сәламәтлек

Алдан аяк киенү

ТАТАРСТАНДА ХАЛЫКНЫҢ 34 ПРОЦЕНТЫ ГРИППКА КАРШЫ ПРИВИВКА ЯСАТКАН

Татарстанда ОРВИ йоктыручылар да, коронавирус белән авыручылар да кимегән. Грипп белән авыруның исә әлегә бер генә очрагы да теркәлмәгән. Бер атна эчендә республикадагы эпидемиологик вазгыять әнә шулай үзгәргән. Әмма белгечләр, октябрь азагы – ноябрь башында вируслы авырулар йоктыручылар саны кисәк артырга мөмкин, дип фаразлый. Шуңа күрә алдан аяк киенә башларга киңәш итәләр.

Республикада коронавирус белән авыручылар саны икенче атна рәттән кими бара. Узган атнада алар 9 процентка кимегән. Бу хакта журналистларга Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсе башлыгы урынбасары Любовь Авдонина хәбәр итте.

– Бер атна эчендә Татарстанда коронавирус йоктыруның 389 яңа очрагы теркәлде. Ковид әле дә күбрәк ОРВИ рәвешендә яки берninди билгеләрсез генә уза. Соңгы арада коронавирустан хастаханәгә ятып дәвалanучылар саны да кими башлады. Узган атнада чир йоктыручыларның 30 процентын дәвалау оешмасына салган булсалар, аннан алдагы атнада бу күрсәткеч 35 процентны тәшкил итә иде, – дип ачыклык кертте белгеч. Сүз уңаеннан, быел республикада 14965 кеше коронавирус белән авырган.

Республикада ОРВИ белән авыручылар да кими төшкән. Гриппның исә әлегә бер генә очрагы да теркәлмәгән. Әмма бу тынычланырга кирәк дигән сүз түгел, ди белгечләр. Любовь Авдонина, грипп белән авыручылар саны октябрь ахыры – ноябрь башында артыр, дип фаразлый. Узган ел республикада грипп һәм ОРВИ белән авыручылар саны 7 ноябрьдә арта башлаган.

– Быел республикада барлыгы 2411000 кешегә гриппка каршы вакцина ясалыр дип көтелә. Бу – республика халкының 60 проценты дигән сүз. Хәзерге вакытта бу күрсәткеч 34 процентны тәшкил итә, – ди Любовь Авдонина. – Кызганыч, әлегә өлкән яшьтәгеләр, хроник авырулары булган кешеләр, студентлар арасында прививка ясатучылар бик аз. Бу эшне якын арада башкарырга тырышсыннар иде. Бигрәк тә студентлар. Алар бик актив. Укудан тыш төрле җирләрдә эшлиләр, кеше күп булган урыннарда йөриләр. Шуңа күрә аларга сәламәтлекне алдан кайгыртырга кирәк.

Сүз уңаеннан, Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы бу көннәрдә коронавирусны дәвалауга булган тәкъдимнәрне яңартты. Анда, хәзер коронавирус сезонлы авыру гына булып кала, диелә. Аның билгеләре ОРВИ вакытында күзәтелгәннәре белән охшаш. Авыру кешенең температурасы күтәрелә, коры ютәл күзәтелә, ул тиз арый, күкрәк читлеге авырта. Моннан тыш тамак авыртырга, күз кабагы ялкынсынырга, борынга томау төшү, ис һәм тәм сизмәү кебек билгеләр дә күзәтелергә мөмкин.

Яңартылган документка ковидны дәвалаганда куллану өчен 13 төрле яңа дару исеме дә өстәлгән. Тәкъдимнәр рәтенә 6–11 яшьлек балаларга ясалырга тиешле «Гам-КОВИД-Вак-Д» вакцинасы да кертелгән.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүзгә-сүз

Илсур ҺАДИУЛЛИН, Татарстанның мәгариф һәм фән министры:

Бөтен кеше дә олимпиада җиңүчесе, артист яки спортчы була алмый. Үз юнәлешеңне табу һәм шунда чыныгу мәслихәт. Иң мөһиме – кешелек сыйфатларын тәрбияләү: көчсезләргә ярдәм итәргә, өлкәннәрне хөрмәтләргә, авыруларны кайгыртырга өйрәнсеннәр. Физика буенча олимпиадада җиңүчедә дә, булачак артист, спортчыларда да әлеге сыйфатлар тәрбияләнергә тиеш.

(«Татарстан» журналыннан)

РОССИЯДӘ – КРЕДИТ

«Работа.ру» хезмәте ил халкыннан ешрак нинди товарларны кредитка алуларын ачыклаган. Сүз уңаеннан, сораштырудан күренгәнчә, россиялеләрнең күпчелегенең (72%) гомерендә бер тапкыр булса да кредит алганы бар икән.

НӘРСӘ ӨЧЕН КРЕДИТ АЛАЛАР?

26%	>> автомобиль
26%	>> электроника
25%	>> фатир
19%	>> ремонт
13%	>> уку өчен түләргә
10%	>> сәяхәт

Ноябрь җылысы

Бу атнада 13 градуска кадәр җылыта. Явым-төшем туктый. Гидрометеоүзәк мәгълүматларына караганда, чәршәмбе – 1 ноябрьдә Татарстан бик җылы һава чолганышында калачак. Явым-төшем ихтималы аз, урыны белән томан. Көндез +7...+12. Төнлә +2...–1 градус. Пәнҗешәмбе – 2 ноябрьдә дә бик җылы һава саклана. Көндез термометрның терекөмеш баганасы +8...+13 градуска кадәр күтәреләчәк. Төнге сәгатьләрдә +2...+7. Көндез аз гына яңгыр сибәләргә мөмкин.

Синоптикларның башлангыч фаразына караганда, җомга – 3 ноябрьдә һава +3...+8 градуска кадәр җылыначак. Яңгыр көтелә. Шимбә – 4 ноябрьдә исә берникадәр суыта: көндез һава температурасы 0...+5 градус чикләрендә тирбәләчәк. Төнлә 0...–2 градуска кадәр төшәчәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

КЫТАЙ: ИКЪТИСАД ЧҮГЕП БАРГАНДА

Дөнья икътисадыннан килгән хәбәрләр куанычлы түгел. Американың фонд базары үткән атнаны кызыл зонада тәгәлләде, ягъни кыйммәтле кәгазьләр очсызланды. Франциядә дизель ягулыгына ихтыяҗ кими. Сентябрь аенда, үткән елның шул чоры белән чагыштырганда, солярка 13 процентка азрак ягылган. Дизель ягулыгын, нигездә, йөк машиналары куллана, димәк, үзеннән-үзе товар ташу кискен кимегән диган нәтиҗә ясала.

Хәбәрләрнең иң шомлысы Кытайдан килә. Алар дәвамлы бурыч кризисына кереп бара. Җирле хакимият органнары финанслаучы компанияләрнең 40 процент тирәсе бурычларына дефолт игълан итәчәк, диләр. Төбәк хөкүмәтләренең гомуми югалтулары 5 триллион доллар – Кытай эчке тулай продукцияның 30 процентына тиң булачак. Evergrande Group компаниясе – Күк асты иленең иң эре девелоперы хәл эчендә: бурычларын түли алмый. Компаниянең кредиторлары аны реструктурлаштыру планына каршы чыктылар. Бу атна башында булачак судта Evergrande Groupны юкка чыгару мәсьәләсе карала. Бик зур компаниянең гамәлдән чыгарылуы кытайлар өчен кыйммәткә төшәчәк. Эш шуның белән генә тәгәлләнсә, Күк асты иле, бәлки, зур мәтәлчекне арткарак чигерер торыр иде. Әмма тагын бер девелопер Country Garden тарихта беренче тапкыр доллар облигацияләре буенча дефолт хәлендә. Ул льготалы чорда облигацияләренең процентларын түли алмады, үткән атнада өстенлекле чор тәгәлләнде. Белгечләр вазгыятьне дефолт вакыйгасы дип бәяли.

Ил эчендә сәяси тотрыксызлык билгеләре шәйләнә. Дәресрәге, югары җитәкчелек, гайкаларны нык кысып, тотрыклылык тәэмин итәргә тырыша. Әле ун ай элек кенә Премьер-министр урындыгында утырган Ли Кэцян үткән атнада көтмәгәндә үлеп китте. Ли Кэцян хәзерге лидер Си Цзиньпинга оппозициядә торган «комсомоллар» төркеменнән һәм Кытайның Америка белән мөнәсәбәтләрен яхшырту тарафдары иде. Ул 68 яшьтә генә һәм сау-сәламәт иде, әмма кирәгеннән артык активлык күрсәтте, диләр. Тоталитар җәмгыять шартларында оппозицион активлыкның сәламәтлек өчен зыянлы гына түгел, ә үтергеч дәрәҗәдә куркыныч икәнен һәркем белә. Элекке бер чиновникның үлеме әллә ни зур вакыйга түгел шикелле. Әмма шулай тоела гына ул. Кытай университетларында Ли Кэцянны искә алу чаралары үткәрмәскә кушылды. 1989 елда Компартиянең элекке лидеры Ху Яобанның җеназасы уңаеннан үткәрелгән искә алу чаралары Пекиндагы Тяньаньмэнь мәйданында зур протест акциясенә әверелгән һәм җитәкчелек яшьләр фетнәсен ул чакта кан белән сугарып кына туктаткан иде. Икътисадый тотрыксызлык шартларында тагын бер Тяньаньмэнь мәйданы кирәк түгел, дип саныйлар Пекинда.

Россиядә

ЗУР ПРОЦЕНТЛАР ОЗАККА КИЛДЕ

Фәләстыйн вакыйгалары Россиядә дә кайтаваз бирә. Россия җитәкчелеге рәсми рәвештә геноцидка каршы чыга. Үткән атнада ХАМАС делегациясе Мәскәүдә булып китте. Әмма якшәмбе кичендә Дагыстанда Израильгә каршы хәрәкәт чамадан узды. Ярсыган халык төркеме Махачкалада Израильдән очып килүче самолетны каршы алды. Киртәләрне җимереп, очу кырына чыгучылар һәм, самолетка үтеп кереп, гыйбриләрне эзләүчеләр булды. Кавказлылар арасында, гыйбри качаклары, Израильдән күчеп килеп, яшәп калу өчен урнашырга теләп, диган имеш-мимешләр таралды. Кайчандыр Фәләстыйнга да гыйбриләрнең качаклар булып килеп, соңыннан хуҗага әверелүен искә төшерделәр. Ярсып, хисха бирелү яхшы нәтиҗәләргә китерми. Тәртип бозучылар катгый җәзага тартылачак. «Российская газета» үз сайтында бу уңайдан язма урнаштырды һәм Дагыстан башлыгы Сергей Меликовның белдерүен бирде.

Ил эчендә тотрыклылыкны саклау өчен зур көч түгәргә туры килә. Икътисадый кыенлыклар шартларында гадәттә экстремизм чәчәк атуга уңай шартлар туа. «Өендә нилләр барын күршеңнән сора», – дип әйтелгән бит әле. Евросоюз Россиягә каршы яңа санкцияләр пакеты әзерли. Аңа кадак, инә, радиатор һәм йорт өчен башка вак-төяк кирәк-яраклар кертелгән. Матвиенко бервакыт, үзебездә кадаклар да җитештермибез, дип шаулаган иде, әле дә җитештерелми икән. Белгечләр, санкция кертелсә, вакытлыча кадак дефициты пәйда булырга мөмкин, диләр. Әмма Кытай тәэмин итәр дигән өмет белдерәләр.

Үзәк банк инфляция контрольдән чыгып китәр дип шикләнә. Ай башында без төп ставканың күтәрелачәген фаразлаган идек. Үткән җомгада фараз көткәннән артык тормышка ашты: процент ставкасы 13тән 15кә кадәр сикерде. Кредит ставкалары егерменең тгге ягыннан күпкә өстенрәк булачак, димәк. Кредит бирү кимер, беренчел взнослар артыр... Үзәк банк хөкүмәтне ипотека кредиты бирүне дә катлауландырырга чакыра. Әмма Силуанов өстенлекле кредит ставкаларының күтәрелмәячәген вәгъдә итә. Ипотеканың 90 проценты өстенлекле.

Кадак җитештерү артык катлаулы эш түгел. Инновацион технологияләр таләп итми, әмма кредит ставкалары югары торганда, бизнес нәрсәдер җитештерә башларга теләрме икән? Югары ставкалар озакка килде, ди Үзәк банк.

МҮКЛИСЕ ДӘ ЧУТЛЫЙСЫ

tatarstan.ru

Агачтан йорт салу җиңеләячәк. Ил Хөкүмәтендә моңа бәйле берьюлы өч закон проектын хуплаганнар. Яңалыкларның асылы нәрсәгә бәйле икәне дә билгеле: җәй азагында узган киңәшмәләрнең берсендә Россия Президенты Владимир Путин агач йорт төзелеше тармагын үстерергә кушты. Әйткән сүз – аткан ук.

Илгиз Харисов Казанда һәм шәһәр тирәсендә йортлар салу белән шөгыльләнүче оешмада эшли.

– Соңгы ике-өч елда кирпечтән, шул исәптән блоктан йорт салу икеләтә һәм аннан да күбрәккә кыйммәтләнде. Агач йортларның бәясе исә якынча 20–30 процентка артты, – ди эшләрне башкаручы. – Йортларга ел башында сорау зуррак иде. Хәзер дә төзибез, әмма ул кадәр үк күп түгел. Бигрәк тә зур мәйданлы төзелешләргә сорау кимеде. Кирпеч йортны күбрәк тышкы матурлыгы һәм аны карап тору артык чыгымнар таләп итмәве өчен сайлыйлар. Агач йортта сулыш алу да рәхәтрәк, билгеле. Төзелеш бәясе таш яки агач «тартма» салу, диварларны эчке яктан җылыту, аны тигезләүгә карап аерыла. Агач йортта ремонт эшләре артык чыгымлы түгел. Әмма таштан салынганында диварларны җылытудан алып, обой ябыштырганчы шактый тырышырга туры киләчәк. Моннан чыгып караганда агач йорт отышлырак, әлбәттә.

Якын арада агач йортларга өстенлек бирүчеләр тагын да артып китмәгәе. Ил Хөкүмәтендә әлеге төр төзелешне үстерүгә бәйле өч закон проектын хуплаганнар. Бу хакта Россия вице-премьеры Виктория Абрамченко аппаратында хәбәр иткәннәр. Әйтүләренә караганда, яңалык «туба»ле булырга тиләүчеләрне намуссыз төзелеш оешмаларыннан саклап кына калмыйча, шәхси торак төзелешенең бәясен киметергә һәм агач йортлар төзелешен арттырырга да булышачак.

Аерым алганда, шәхси торак төзелешендә, шул исәптән агачтан йорт салучылар өчен дә, эскроу-счетны гамәлгә кертергә тәкъдим иткәннәр. Билгеле булганча, бүген мондый тәртип өлешләп төзелештә катнашуда гамәлдә. Ягъни төзелеш эшләре тәмамланганчы, милек сатып алырга теләүчеләрнең акчасы аерым хисап счетында саклана. Төзелеш оешмасына ул объект кулланышка тапшырылгач кына күчә. Төзелештә өлешләп катнашудагы кебек үк, 10 миллион сумга кадәр акча иминиятләштереләчәк, дип фаразлана. «Яңалык гамәлгә кергәч, агач йорт сатып алырга теләүчеләр төзелеш барышында үзләрен ышанычлырак хис итәчәк», – дигәннәр Хөкүмәттә.

Тагын бер үзгәреш агач йортларның бәясенә кагыла. Әлеге төр хезмәтне өстәмә кыйммәткә салымнан азат итәргә тәкъдим иткәннәр. Димәк, төзелеш тә очсызланачак. «Бүген банклар еш кына мондый төзелешләргә ипотека бирүдән баш тарта. Чөнки эшнең тулысынча башкарылып чыга алуына шикләнәләр. Алга таба төзелеш оешмалары турындагы бөтен мәгълүмат реестрда сакланачак һәм алар, үз бурычларын тулысынча башкармыйча, акчаны ала алмаячак», – диган Виктория Абрамченко.

Хәтерләсәгез, бу елның августында узган киңәшмәләрнең берсендә Россия Президенты Владимир Путин тармакны үстерергә кирәклегенә басым ясады. Чарада күпкатлы агач йортлар төзелеше турында да сөйләшелгән. Росстат мәгълүматларына караганда, быелгы ил күләмендә 14,2 миллион квадрат метр агач торак төзелгән. Алдагы ел белән чагыштырганда, бу – 31 процентка күбрәк. Агымдагы ел азагына кадәр иса әлеге күрсәткеч якынча 20 процентка үсачәк дип фаразлана.

Сан

Росреестрның Татарстандагы идарәсеннән алынган мәгълүматларга караганда, былтыр Татарстанда **15 мең**нән артык шәхси торак йорт кадастр исәбенә куелган. Аларның гомуми мәйданы **2 миллион** квадрат метрдан да артып киткән. Барлык йортларның **7 мең**гә якыны – кирпечтән, **2 мең** чамасы агачтан салынган.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Ноябрь үзгәрешләре

➤ **Кибеттә, банкта яки башка җирдә өстәмә товарлар, хезмәтләр сатып алырга мәҗбүриләүчеләр өчен штрафлар кертелә.** Иң зур штраф күләме – 40 мең сумга кадәр. Шулай ук кулланучы дәгъвасын карап тикшерүдән баш тарткан өчен дә җаваплылык (300 мең сумга кадәр штраф) күздә тотыла.

➤ **Очучыларның, шахтерларның пенсиясе арта.** Өстәмә акча зарарлы, хәтәр, киеренке һәм авыр эш шартлары өчен бирелә.

➤ **25 мең сумнан 1 миллион сумга кадәр бурычлылар, судка бармыйча гына, банкрот дип тану турында гариза тапшыра алачак.** Балалар өчен бердәм пособие генә алып, башка керемгә, мөлкәткә ия булмаучылар һәм пенсионерлар – әҗәтне мәҗбүриләп түләтә башлаганнан соң 1 ел узгач, башкалар – 7 ел узгач, шушы мөмкинлектән файдаланачак.

➤ **Технологик компанияләргә, кече технологик компанияләргә дәүләт ярдәме күрсәтелә башлаячак.** Аларның исемлеген булдыру кагыйдәләре билгеләнәчәк. Шулай итеп, югары технологияле кече компанияләргә булышу, зур сәнәгать предприятиеләрендә алдынгы эшләнмәләрне гамәлгә кертү мөмкинлеге ачыла.

➤ **Идарәче оешмалар, торак милекчеләре ширкәтләренең уставлары һәм килешүләрен газ җиһазларына техник хезмәт күрсәтү турында яңа законга туры китерү вакыты тәгәлләнә.** Документ нигезендә, хәзер барлык газ челтәрләрен бер генә оешма – газ бүлү оешмасы гына карап тотачак.

ДЕПУТАТЛАР ИГЪТИБАРЫНА

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык сигезенче утырышы **2 ноябрь** көнне Дәүләт Советы утырышлар залында дәвам итәчәк (**10.00 сәгатьтә** башлана).

Дәүләт Советы депутатлары Дәүләт Советы бинасында **2 ноябрьдә 8.00 сәгатьтән** теркәләчәк.

Белешмәләр алу өчен телефон: **267-63-62**.

УНИКАЛЬ ЗАВОД

Яңалык

Татарстанда гына түгел, Россиядә дә мондый заводка тиңнәр юк. Теләче районында «Август-Агро» компаниясенең иң заманча симәнә заводы гадәти режимда эшли башлады. Аның үзенчәлекләрен без дә барып күрдек.

Биредә тузан да, бер-беренне ишетмәслек көчле тавыш та юк. Бар җирдә тәртип, төгәллек, чисталык һәм тизлек хөкем сөрә. Заводны бөтен дөньяда орлыкчылык буенча иң уңышлы эшләп килүче Petkus компаниясе төзегән. Компаниянең Идел төбәге буенча директоры Андрей Натальин биредә иң көчле, заманча җиһазлар куелганлыгын әйтте. Заводта 15 кеше эшли. Линия бер сәгатькә 10 тонна бодай орлыгы эшләп чыгара.

– Технология линиясе уникаль. Моңа охшаш заводлар дөньяда бар, ләкин аны тулысынча кабатлый торганнары юк. Бик көчле һәм сыйфатлы ул, – диде директор.

«Август-Теләче» агрофирмасы директоры Алмаз Хәйруллин әйтүенчә, моңа кадәр оешмада ашлык киптерү комплексы төзелгән. Биредә сәгатенә 50 тонна ашлыкны чистартып киптерергә мөмкин. Орлык җитештерү заводы исә – әлеге проектның икенче этабы. Алмаз Хәйруллин аңлатуынча, алдан чистарту этабында орлыклык материалның яхшыларын сайлап алалар, кабыкларыннан, саламнан, тузан, минераль һәм органик кушылмалардан арындыралар. Шуннан соң ашлык сакланырга куела. Икенче этапта исә калган кушылмалар, чүп үләннәрнең орлыклары, начар сыйфатлы ашлыклар төшеп кала. Бөтен шартларга туры килә торган симәнәләрне зурлыгы, авырлыгы, төсе буенча аерып алалар. Бу эшләр орлыкларның барысы да бер вакытта сыйфатлы тишелеп чыгуы өчен кирәк. Көнбагыш, кукурузлар кебек бик нәзберек культураларны эшкәртер өчен аерым технология каралган. Киләчәктә биредә Россия базары өчен яңа булган фотосепарация технологиясен дә кулланырга планлаштыралар.

Шуннан соң орлык, чистартылып, кирәкмәгән вак-төякләрдән арындырылгач, авырлар һәм корткычларга каршы препаратлар белән эшкәртелә. Бу линиядәге җиһазлар орлыкларны препаратлар белән бернчә кат эшкәртү мөмкинлеген бирә. Монда да яңа технологияләр кулланылган. Бу, үз чиратында, орлыклар бер-берсенә ышкылып, зыян салмасын өчен эшләнелә.

Татарстанда «Август-Агро» оешмасының 200 мең тоннага серүлек җире бар. Әлеге заводта җитештереләчәк орлыкларның 70 проценты үз хуҗалыклары өчен тотылса, калганнары республиканың башка оешмаларына җибәрәчәкләр.

avgust.com

– Завод югары сыйфатлы орлыклар алу максатыннан төзелде. Аралап алынган, чистартылган, бөҗәкләргә каршы препаратлар белән эшкәртелгән орлыкларны теләге булганнар бездән сатып та ала алачак, – диде «Август-Агро» компаниясенең җитештерү буенча директоры Илнар Харисов.

Аның сүзләренчә, Теләче бүлекчәсен симәнәчелек белән шөгыльләнү үзәге итеп сайлап алуның берничә сәбәбе бар.

– Беренчедән, район урнашу урыны буенча отышлы. Өч ел биредә эшләү вакытында районның һава шартлары иң оптималь булуын күрдек. Монда теләсә нинди культураны үстереп була. Икенчедән, җир кишәрлекләре уңайлы, чагыштырмача тигез. «Август-Теләче» элиталы симәнә чәчә, арттыра һәм башка агрофирмаларга тарата. Быел без сынау участогында төрле культураларның 42 сортын чәчтек. Киләчәктә аларның иң уңышлыларын сайлап алачакбыз. Беренче чиратта Россия сортларына өстенлек бирәләчәк. Иң уңышлыларын сайлап алырга кимендә өч ел кирәк. Зур производствога кертеп җибәрер өчен, тагын шуның кадәрле вакыт таләп ителә, – диде ул.

Әлеге проект оешмага 600 млн сумга төшкән. Хәзерге вакытта биредә беренче чиратта элиталы һәм продуктивлыгы югары бодай һәм борчак культураларын җитештерәчәкләр. Ә гомумән алганда, киләчәктә заводта барлык төр культуралар да җитештереләчәк.

Быел «Август-Теләче» агрофирмасы тагын бер зур уңышка ирешкән. Алар люцернадан дүрт тапкыр уңыш алган. Билгеле булганча, күпчелек хуҗалыклар аны сезонга ике тапкыр гына чабып алуга ирешә, ә биредә дөрес технологияләр кулланып, уңыш күләмен арттырганнар. Беренче тапкырын башкалар тотынганчы ук чабып алган булсалар, соңгысын исә сентябрьдә генә җыеп урнаштырганнар. Соңгы чабуда 600 тонна яшел масса җыеп алынган. Бу 220 баш терлекне егерме көн ашатырга җитәчәк, ди белгечләр.

– Республиканың көнчыгыш районнарында яңгырлар булмау сәбәпле, андагы бүлекчәләр терлек азыгын җитәрлек күләмдә әзерли алмадылар. Шуңа күрә без үзебез әзерләгән сенажны аларга җибәрәбез, – диде Алмаз Хәйруллин.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Ватан хакына

СЕЗНЕ ӨЙДӘ КӨТӘЛӘР, БАЛАЛАР!

Арчада яшәүче 34 яшьлек Илгиз Гыйззәтуллин узган елның 29 сентябрендә повестка ала. Аңа кадәр повестка якын дусты, күршесе Айдар Вәлиевкә килә. Илгиз, дустының китәсен белүгә, анда аны үзен генә җибәреп булмый, дип әйткән була. Повестка озак көттерми, өч көн эчендә үзен дә чакырталар.

«Татар-информ»

Айдар белән бергә уйнап үсә, бер мәктәптә, бер сыйныфта, бер партада утырып укый алар. Бергә армиягә баралар. Инде менә махсус хәрби операциядә дә бер ротага эләгәләр. Хәзер ике күршегә – бер хәсрәт. Ятсалар да, торсалар да, уйлары – уллары турында. Айдарның әнисе Гүзәл апа да, Илгизнең әнисе Фирдәвес апа да, балалары исән-имин кайтсын, дип дога кыла. Егетләрнең язмышы өчен бөтен урамнары белән борчылалар икән. Хәл белмәгән көннәре юк, гел ярдәм итәләр, ди әниләр.

– Ирем Исмәгыйль белән ике малай үстердек. Олысы Ирек исемле. Әле ярый анысы да китмәде, дип сөенәм. Энесенә повестка килгәч, мин дә барам, дигән иде. Аннары Илгиз янына барып кайтты. «Энем анда, мин монда нишләп ятыйм?!» – дип өзгәләнде. Көчкә туктаттым. «Әтиегез белән олыгаеп киләбез, безне кем карар? Кемгә ышаныйк?!» – дидем. Ирегем китмәсә дә, егетләрне ташламый. Районнан ярдәм җыеп илтә. 9 тапкыр барып кайтты инде, – ди Фирдәвес апа. – Ирек улым бу эшләре хакында сөйләргә кушмый. Кеше күрсен, дип йөрми бит. Газиз туганы өчен өзгәләнеп бара. Без аларны бик тә туган җанлы итеп үстергәнбез икән. Холыклары буенча икесе ике төрле булса да, күңелләрендә ярату, бер-берсен якын итү икесендә дә бер үк. Нәселебездә туганнар дус-тату безнең. Үземнең апам да, иремнекеләр дәербөтен булып яшибез.

Фирдәвес апаның уллары гаиләле. Хатыннары белән сабыйлар сөяләр. Илгизнең Ватанны сакларга китүе аларны тагын да берләштергән. Фирдәвес апаның исә элеккедәй яшәгәне юк икән инде. Сөйләшкән арада да әллә ничә мәртәбә елап алды. Улын бик сагына ул.

– Армиядә булса бер хәл иде. Әле анда да бик авырлык белән җибәрдем. Тугыз ай карынында йөрткән сабыеңны чыгарып җибәрәсе киләме соң? Илгизем гәүдәле иде. Армиядә чакта: «Олыраклар кыерсытмыймы?» – дип сорап тордым. Бер дә зарланмады. Беraз хезмәт иткәч, яңа гына килгән солдат егетләре өчен дә борчылып шалтыраткалый идем. «Балам, аларның да әниләре бар. Алар да өзгәләнәдер. Берүк кыерсытмагыз», – дип тукып тордым. Ана өчен баласын читкә җибәрү бик авыр. Егетләрнең илне сакларга тиешлеген дә аңлыйм мин. Тик йөрәккә әмер биреп буламы соң?! – ди Фирдәвес апа. – Әле менә район җитәкчелеге бер арба утын алып килеп бирде. Шалтыратып, ял йортына барасыгыз килмиме, дип тә сорадылар. Балам бер кашык җылы аш ашыймы икән, дип өзгәләнгәндә, ничек ял итә алыйм?! Тавышын бер ишетергә, бер күрергә тилмереп торам. Ике тапкыр ялга кайтып китсә дә, күреп, яратып туя алмадым.

Хәбәрләшү, дигәннән, Илгиз хатыны белән элемтәгә чыга икән. Киленнәре исә әти-әнисенә барысын да җиткереп тора. Әле менә Илгиз әниләренә видеоэлемтә аша шалтыраткан. Бик тә сагынуын әйткән.

– Йөрәгем урыныннан кузгалды. Баламны күреп сөйләшү дулкынландырды. «Бар да яхшы, әни», – дип кенә тора. Мунча кирәсе көннәре икән. Битләре сыдырылган. Эчем пошты инде. Ялгыш бәрелдем, дигән була. Әйтәм бит, батыр йөрәкле, Ватанга кирәкле бала үстергәнбез. Горурланам. Әнә шул горурлык яшәтә инде мине. Кичләрен тагын уйга калам, балам сагындыра. Йоклый аламы, ашаганмы, туңмыймы икән, дим. Ничә яшьтә булса да, алар минем өчен сабый бит. Шөкер, гаиләләре бар. Улымны көтүче мин генә түгел. Киленем, кызы өзелеп көтә.

Фирдәвес апа, улым исән-имин кайтсын дип догалар укыйм, ди. Илгиз үзе дә, әни, дога кылыгыз, дип әйтә икән. Киткәндә әнисе улына дога язып биргән. Аның яртысы өйдә калган, яртысы Илгизнең куен кесәсендә икән.

– Ни генә дисәләр дә, ана күңелен алдап булмый. Минем йөрәк сизеп тора. Балам өчен борчылып яшим. Өлешчә мобилизация тормышны икегә бүлсә дә, күңелне төшермәскә тырышам. Баласын көтүче һәр ана аның исән-имин, үз аякларында кайтуын күрсә иде, – ди Фирдәвес апа. – Ана догасы пәрдәләрсез кабул булыр, диләр. Әнә шуңа да балам өчен гел Аллаһы Тәгаләдән исәнлек сорыйм. Улларыбызны фәрештәләр саклап йөртсә иде. Сезне өйдә көтәләр, балалар!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

ВЛАДИМИР АЛЕКСАНДРОВИЧ ПОПОВ (24.06.1924 – 27.10.2023)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды. Россия һәм Татарстанның танылган рәссамы, каллиграфия остасы Владимир Александрович Попов 100 нче яшендә бакыйлыкка күчте.

Владимир Попов 1924 елның 24 июнендә Мариуполь шәһәрендә хәрбиләр гаиләсендә дөньяга килә. 1941 елда унҗиде яшендә үз теләге белән фронтка китеп, бөтен сугыш юлын уза. Сугышчан батырлыклары өчен ике Ватан сугышы ордены, Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр белән бүләкләнә. Инде фронтта ук хәрби рәссамнарның күчмә күргәзмәләрендә катнаша. Сугыштан соң тәүге шәхси күргәзмәләре оештырыла. 1947 елда Казан сәнгать училищесына укырга керә. Укуын тәмамлаганнан соң Татар сәнгать фондында эшли.

Илленче елларда илнең сәнгать тормышында актив катнашып, табигатькә, чирәм җирне үзләштерүгә багышланган монументаль әсәрләр сериясен булдыра. Станоклы графика өлкәсендә табигать күренешләре, индустриаль һәм архитектура пейзажлары жанрларында әсәрләр иҗат итә. «Растут города» (1959–1961), «Трасса» (1961), «Нефть Татарии» (1964), «Уренгой – Ужгород» (1965), «КамАЗ» (1972), «БАМ от нулевого километра до Чары» (1986), «Старая Казань», «Новая Казань» (икесе дә – 1971), «Набережные Челны строятся» (1972), «Проходчики недр» (1984), «Земля Челнинская» (1989) һәм башка серияләре республиканың гына түгел, бәлки бөтен илнең сәнгати елъязмасына әйләнде. Аның әсәрләре композицион тулылыгы, монументаль образлылыгы, хислелеге белән аерылып торды.

1990 нчы еллардан башлап, Владимир Александрович каллиграфия һәм шәмаил сәнгатенә өстенлек бирде. Ул «Шедевры культового зодчества России», «Мусульманские святыни Востока, Татарстана» кебек атаклы әсәрләрен иҗат итте, шулай ук ислам каллиграфиясе өлкәсендә 700дән артыграк хезмәтне («Черный камень», «Вседарящий», «Творец», «Создатель», «След Пророка», «Булгары», «Ханская Казань», «Из единого начала» шәмаилләре; гарәпчә дини тугралар серияләре, илебезнең сәяси һәм иҗтимагый эшлеклеләре, мөселман дөньясы руханилары һәм корольләрнең исемле тугралары) дөньяга чыгарды.

Владимир Поповның югары дәрәҗәдәге осталыгы һәм намуслы хезмәте зур бүләкләр белән билгеләнде. Алар арасында – «Фидакарь хезмәт өчен» медале, Татарстан Республикасы Мактау грамотасы, «ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе», «Татарстан Республикасының халык рәссамы» һәм «Россия Федерациясенең атказанган рәссамы» дигән мактаулы исемнәр. Ул ЮНЕСКО каршындагы Халыкара сынлы сәнгать ассоциациясе әгъзасы булды. 2014 елда Габдулла Тукай исемендәге Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе лауреаты һәм Россия Мөфтиләр шурасының Фәизханов премиясенә лаек булды.

Владимир Александрович гомеренең соңгы елларына кадәр данлыклы иҗади юлын дәвам итеп, илһам, ватанпәрвәрлек, югары дәрәҗәдә хезмәт сөючәнлек һәм җаваплылык үрнәгенә әйләнде. Ул кешеләргә карата ихтирамлы мөнәсәбәте, тынычлык сөючәнлеге, дөньяны танып белүгә гаять зур омтылышы, үз эшенә иксез-чиксез тугрылыгы белән аерылып торды.

Талантлы рәссамның якты истәлеге күңелләребездә мәңге сакланыр.

Р.Н. МИҢНЕХАНОВ, М.Ш. ШӘЙМИЕВ, Ф.Х. МӨХӘММӘТШИН, А.В. ПЕСОШИН, Ә.Ә. СӘФӘРОВ, И.Х. ӘЮПОВА, И.Р. МЕТШИН, Р.М. НУРГАЛИЕВА



ТАШЛАМАЛАР һәм ГАРАНТИЯЛӘР HEROES.TATAR 117

- РОССИЯ ОБОРОНА МИНИСТРЛЫГЫ ХИСАБЫНА ТУПЛАНМА-ИПОТЕКА СИСТЕМАСЫ АША ТИЗ АРАДА ТОРАК САТЫП АЛУ МӨМКИНЛЕГЕ
- ХЕЗМӘТ УРЫНЫННАН ТОРАК ЯКИ ТОРАКНЫ НАЙМГА АЛЫП ТОРГАН ӨЧЕН КОМПЕНСАЦИЯ
- ХӘРБИ-МЕДИЦИНА УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ БУШЛАЙ ТИКШЕРЕНҮ, ДӘВАЛАНУ һӘМ РЕАБИЛИТАЦИЯ УЗУ
- ФЕДЕРАЛЬ БЮДЖЕТ ХИСАБЫНА ГОМЕРНЕ һӘМ СӘЛАМӘТЛЕКНЕ ИМИНИЯТЛӘШТЕРҮ
- 20 ЕЛ ХЕЗМӘТ ИТКӘННӘН СОҢ ТАШЛАМАЛЫ ПЕНСИЯ АЛУ ХОКУКЛАРЫ
- ХӘРБИ ХӘРӘКӘТЛӘР ВЕТЕРАНЫ СТАТУСЫ һӘМ ТИЕШЛЕ ТАШЛАМАЛАР
- КРЕДИТ һӘМ САЛЫМ КАНИКУЛЛАРЫ
- БАЛАЛАРНЫ ВУЗДА БУШЛАЙ УКЫТУ
- БАЛАЛАРГА ҖӘЙГЕ САВЫКТЫРУ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА БУШЛАЙ ЯЛ
- КОНТРАКТ БУЕНЧА ХЕЗМӘТ ИТҮЧЕ ХӘРБИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРГӘ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ СУБЪЕКТЛАРЫННАН БЕРДӘМ ӨСТӘМӘ ТҮЛӘҮЛӘР, ТАШЛАМАЛАР һӘМ ГАРАНТИЯЛӘР

ЫШАНУДАН ТУКТАМА!

Спорт

«Зенит-Казан» Россия Суперкубогы иясе булып танылды. Үз тарихында 9 нчы мәртәбә! «Рубин» октябрьдә бер мәртәбә дә оттырмады. Шулай итеп, турнир таблицасында өскәрәк күтәрелә алды. «Ак барс» исә рәттән ике мәртәбә җиңелүгә дучар булды. Алда СКА һәм «Салават Юлаев» белән очрашулар көтә. Татарстан спортындагы төп вакыйгаларга кыскача күзәтү.

Тугызынчы мәртәбә

Россиядә волейбол уйный башлаганга бер гасыр тулу хөрмәтенә быел 100 еллык Кубогы узды. Җиңүчене октябрь башында Калининградта ачыкладылар. Финалда «Зенит-Казан» белән Мәскәү «Динамо»сы уйнады. Безнекеләр матч башында рәттән ике сетны зур өстенлек белән отса да, очрашу көндәшләрнең җиңүе белән тәмамланды. Безнекеләр суперлигадагы сезонны да авырлык белән башлады. Беренче очрашуда белорусларның «Шахтер» командасын көчхәл белән отса, икенчесендә 0:3 исәбе белән Новосибирск «Локомотив»ына оттырдылар. Өченче турда «Зенит-Казан» янә Мәскәү «Динамо»сы белән очрашты. Әлеге матчта берочтан Россия Суперкубогы иясе дә ачыкланды.

Бу юлы Казан командасы Калининградтагы хаталарны төзәтеп, көндәшкә бер сет та бирмәде. «Мондый зал күргән юк иде! Команда өчен шундый авыр вакытта бу кадәр тамашачы килер дип уйламадык та. Шуңа күрә җиңү сөенече тагын да артты», – диде очрашудан соң «Зенит-Казан»ның баш тренеры Алексей Вербов. Очрашуны карарга «Волейбол үзәге»нә 4850 тамашачы җыелды.

zenit-kazan.com

Дәүләт Советы Рәисе, Татарстанның Волейбол федерациясе президенты Фәрит Мөхәммәтшин «Зенит-Казан» командасы җитәкчелеге һәм уенчыларына Россия Суперкубогында җиңүләре уңаеннан котлау телеграммасы юллады. Парламент башлыгы әйтүенчә, мондый уңышлар – уенчылар, тренерлар, белгечләр һәм менеджерларның көндәлек киеренке хезмәте нәтиҗәсе. «Тулы трибуналар алдында команда үз җанатарларына спорт бәйрәме бүләк итте», – дигән ул котлау телеграммасында. Фәрит Мөхәммәтшин сүзләренә караганда, спортчыларның яхшы уены республикада профессиональ волейболның югары дәрәҗәдә үсүен һәм аның татарстанлылар арасында популярлыгын тагын бер кат раслый.

Очколы октябрь

«Рубин» белән «Балтика» арасындагы уенны күрү өчен «Ак барс Арена»га җыелган тамашачылар саны исә 3 меңгә дә тулмады. Нишләмәк кирәк, һава торышы футбол карарлык түгел. «Рубин» да егылып китеп тамаша кылырлык уен күрсәтми. Калининград командасына каршы узган очрашу 1:0 исәбенә тәмамланды. Казан футболчылары хәлиткеч тупны 88 нче минутта гына кертә алды. Гол – Аргентина футболчысы Валентин Ваданыкы. Очрашуда Албания һөҗүмчесе Мирлинд Дакуның юклыгы нык сизелде. Хәтта баш тренер Рәшит Рәхимов та команданың уенында бу егеткә бәйлелек барлыгын таныды. Гәрчә остазлар мондый сүзне әйтергә бик тырышмаса да. Гомумән, бүгенге «Рубин»ның асылын чит ил уенчылары тәшкил итә. Казан командасында Балкан илләреннән генә дә 6 футболчы чыгыш ясый.

Әнә шулар ярдәмендә «Рубин» октябрьдә 3 очрашуның икесен үз файдасына төгәлли алды. Тагын берсендә ничьяга уйнады. Август һәм сентябрьдә Рәшит Рәхимов футболчылары нибары берәр тапкыр гына җиңү тәмен татый алды. «Балтика»ны откannan соң Казан командасы турнир таблицасында 11 нче урынга күтәрелде. «Рубин»ның 16 очкосы бар. Алда баручылар исемлеге дә игътибарны җәлеп итә: «Краснодар», «Зенит» һәм «Крылья Советов». Беренче өч урында Мәскәүдән бер команда да юк.

Яшкин гына аз

«Ак барс»та барысы да киресенчә. Ике чит ил уенчысы бар-барын. Әмма Белоруссиядә туып-үскән Кристиан Хенкель белән чех хоккей мәктәбендә тәрбияләнгән Дмитрий Яшкинны легионер дип әйтергә тел әйләнми. Яшкин – Казан командасында иң күп алка кертүче уенчы. Әмма ул гына җитми. Узган атнада «Ак барс» «Лада» һәм «Нефтехимик»ка оттырды. Тольятти командасына каршы узган очрашуда Вадим Шипачев уйнамады. Түбән Камада исә Александр Радулов та бозга чыкмады. Баш тренер Зиннәтулла Билалетдиновның фикере мондыйрак: әйе, бу егетләр шәп уйный, әмма башкалар да шәп уйнарга, алка кертергә һәм җиңү яуларга тиеш. Бәйлелек барлыкка килә икән, чемпионлык турында уйлыйсы да юк. Дөрес, көндәшләр дә төшеп калганнардан түгел. КХЛга әйләнеп кайткан «Лада» Көнчыгыш конференциясендә беренче урынга күтәрелде. «Нефтехимик» соңгы 8 очрашуда 7 тапкыр җиңүгә иреште.

Әлеге атнада «Ак барс»ны җитдирәк көндәшләр көтә. СКА белән «Салават Юлаев» бу сезонда әлегә лидерлар сафына кермәсә дә, мондый очрашуларга тамашачы да, уенчылар да аерым игътибар бирә.

Әйләнә-тирә

Чиста булачак!

Татарстанда «ЧИСТАБУЛАЧАК» яшьләр экологик хәрәкәте оешканга 9 ел тулды. Шушы вакыт аралыгында әлеге хәрәкәткә 10 мең кеше кушылган. Татарстан экологлары белә: алардан башка республикада бер генә чара да узмый. Алар – гел беренче. Араларында мәктәп укучылары да, студентлар да, хәтта өлкән яшьтәге кешеләр дә бар. Барысын да бер теләк – Җир-ананы саклау берләштерә.

tatarstan.ru

Шушы көннәрдә алар ел буе эшләгән эшләренең әҗерен алды. Иң активларны сәхнәдә котладылар. Быел активистлар катнашында мәктәп һәм бакчаларда экологияне саклау темасына багышланган 500дән артык дәрес үткәрелгән. 9 ел эченә мондый чараларның саны 1 мең 200дән артып киткән. «ЧИСТАБУЛАЧАК» хәрәкәте 1 меңнән артык өмә уздырган.

Экологик хәрәкәтнең төп бурычларыннан берсе – балалар бакчалары, мәктәпләр, урта һөнәри һәм югары уку йортларында экологияне саклауга багышланган дәресләр оештыру. Алар көнкүреш калдыкларын аерым җыю, үзеңдә экологияне саклау гадәтен тәрбияләү, республиканың табигый байлыклары һәм сирәк очрый торган хайваннар турында сөйлиләр. Кыскасы, үзләре кебек булырга өндиләр.

2023 елда әлеге хәрәкәт катнашында Россия күләмендә 4 экологик акция уздырылды. Анда 800дән артык кеше катнашты. Араларында үз проектларын булдырып, грантлар отучылар да бар.

Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары Егор Тарнавский хәрәкәт активистларын котлау чарасында сүзен яшьләр хәрәкәтенә рәхмәт әйтүдән башлады.

– Безнең киләчәк өметле. Артыбызда 10 мең яшь эколог тора. Димәк, табигать – ышанычлы кулларда, – ди ул. – Сездән башка берни эшләп булмый. Сез бик актив. Экология олимпиадаларында катнашып, җиңү яулыйсыз. Экологик диктант язып, үзегезнең белемнәрне күрсәтәсез. Бөтенроссия күләмендә узучы «Россия суы» акциясе өчен рәхмәт сезгә! Берничә ел беренчелекне алуда сезнең дә өлеш бар. Гомумән, республиканың экологик хәлен яхшыртуга өлеш керткән битараф булмаган һәркемгә чиксез рәхмәт.

Россия экология җәмгыятенең Татарстан бүлеге җитәкчесе Азат Җиһаншин да яшь буынга рәхмәтле булуын яшерми.

– Бүген табигатьне саклауга үзебездән өлеш кертеп, туасы балаларга чиста, матур табигать, саф һава калдырабыз, – ди ул.

Татарстан Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты рәисе урынбасары Таһир Һадиев яшьләргә табигатьне саклауда уңышлар теләде.

Диләрә Сафинаның «ЧИСТАБУЛАЧАК» хәрәкәтенә кушылганына – 4 ел.

– Экология темасы гаиләбезгә якын. Бабам урманчы булып эшләгән. Аның табигатьне яратуы әтиемә дә күчкән. Безнең өйдә генә түгел, ишегалдыбызда, урамыбызда чисталык. Берәү дә чүбен теләсә кая ташламый. Агачлар да утыртабыз. Авылларга кайтып, чишмәләрне чистартабыз, – ди Диләрә. – Казансу янәшәсендә генә торгач, җәен күңел ачып киткән кешеләрнең артыннан да безгә җыештырырга туры килә. Шул шешәләр, чүпчар суга эләгеп, балыкларга зыян килмәсен, дибез. Кеч-кенәдән күңелгә сеңгәнне берничек тә башкача эшләп булмый. Башкаларга да табигатьне яратырга, артыңнан җыештырырга, чисталык турында онытмаска киңәш итәм.

Сүз уңаеннан, хәрәкәткә яшьләр өстәлеп тора. Иң активларны котлаган көнне исә 10 меңенче булып кушылган кызны да тәбрикләделәр. Тәтеш районы кызы Азалия Абделманова (рәсемдә уртада) да хәзер табигать сагында!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

АРХЕОЛОГЛАРНЫҢ УҢЫШ БӘЙРӘМЕ

Яңа хезмәт

Күмәк көч тау күчерә, дип юкка гына әйтмәгәннәрдер. Әмма бүген сүзебез – тау түгел, ә «Идел-Урал археологиясе» дип аталган җиде томлык басма хакында. Шулай да чагыштыру туры килеп тора. Күләме ягыннан да, эчтәлеге ягыннан да колач җитмәслек хезмәт булган ул. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә шушы басманы тәкъдим итү кичәсе булды.

– Һич тә арттырып әйтмим. Бүген кулыбызга алган басма – республикабыз өчен генә түгел, ә бәлки Россия өчен дә уникаль хезмәт, – диде Татарстан Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов, бәя биреп. – Әйтергә кирәк, әлеге юнәлеш буенча да Татарстан башка төбәкләрдән аерылып тора. Инде 1878 елда ук Казан университеты каршында Археологлар җәмгыяте төзелгән. Бу исә – фәнни хезмәтләргә бездә элек-электән зур игътибар бирелгән дигән сүз. Нигезебез нык, шуңа күрә эшебез дә күзгә күренеп алга бара. Казу эшләренең беркайчан да тукталганы юк. Безнең өчен археология юнәлеше бик кадерле. Бу проектны эшләү планын инде 1980 нче елларда ук археолог, тарих фәннәре докторы Альфред Халиков күтәреп чыккан иде. Аның хыялларын бүген, ниһаять, тормышка ашыра алдык. Әмма бу – археологлар эшенә нәтиҗә ясау гына түгел, киресенчә, киләчәккә планнар кору мөмкинлеге. Чөнки без хәзер кайсы чорда нәрсә өйрәнелми калганын, кайсы вакыйгаларга күбрәк игътибар бирергә кирәклеген тәгаен белдек.

«Татар халкының милли тәңгәллеген саклау» программасы кысасында «Идел-Урал археологиясе» җиде томлыгы инде 2016 елда әзерләнә башлаган. Авторлар коллективы да бик саллы. Аның составында 100 тикшеренүче бар. Алар – Казан, Мәскәү, Уфа, Ижау, Самара, Йошкар-Ола, Чабаксар, Саранск, Әстерхан, Сыктывкар, Киров шәһәрләрендәге эре фәнни

үзәкләрнең әйдәп баручы археологлары. Бу томнарны әзерләүдә барлыгы 15 төбәк катнашкан.

Әлеге басма археологларның ярты гасырлык эзләнүләр тәҗрибәсенә нигезләнгән. Ни өчен бу хезмәтләрне берләштерергә булганнар соң? Чөнки галимнәрнең мондый тикшеренүләре озак вакытлар җыелып килгән археологик мәгълүматларга яңача караш булдырырга ярдәм итә, Идел-Урал төбәгендә борынгы заманнан алып бүгенге көннәргәчә яшәгән халыкның тарихын төрле яклап өйрәнергә нигез булып тора.

Археологларның шатлыгын уртаклашырга Россия Фәннәр академиясенең археология институты директоры Петр Гайдуков та килгән иде.

– Моннан 50 ел элек Россия буенча нәкъ менә шушындый эшне башларга кирәклеге турында сүз булган иде. Туксанынчы еллар мәрәкәсе бу теләкләргә чик куйды, әмма тамырдан өзеп ташлый алмады. 2001–2005 елларда 18 томны чыгара алдык. Исәбебез – 20 томга җиткерү. Бу басма илебезнең барлык регионнарын да үз эченә алган. Дөрес, төбәкләр үзләре дә эшли. Әмма Татарстандагы кебек хезмәт әлегә беркайда да юк. Бүген – археологларның уңыш бәйрәме. Сез бүген барысы өчен дә үрнәк булып торасыз. Шуңа күрә бу басманы тиз арада ил буйлап таратырга кирәк.

Әлбәттә инде, кичәдә нигездә җиде томлыкның авторлары, мөхәррирләре катнашты һәм чыгыш ясады. Таш, энеолит һәм бронза, тимер гасырлар, халыкларның бөек күчеш чоры, урта гасырның төрле чорлары... Һәрберсе үзе эшләгән томлыкның мөһимлеген расларга тырышты. Урта гасырга кагылышлы соңгы томнарны тарих фәннәре докторы Фаяз Хуҗин алып барган.

– Иң кызыгы безнеке булды, – диде ул, уенын-чынын бергә кушып һәм дәлилләп тә куйды, – чөнки бу томнарның эчтәлеге хәзерге көнгә бәйле. Әйтергә кирәк, Казан ханлыгы чоры археологлар тарафыннан бик өйрәнелмәгән. Моның сәбәбе дә бар, чөнки язма чыганаклар исән калган, галимнәр күбрәк шуларга таяна. Археологларга бу бушлыкны тутырырга, казу эшләре алып баруны җәелдерергә кирәк. Мәсәлән, Зөя утравын гына алып карыйк. Беренче Президентыбыз Минтимер ага Шәймиев бу эшне башлап җибәрмәсә, археологлар җәлеп ителмәсә, әле андагы тарих һаман да җир астында ятар иде.

Археология эшләренең чикләре тагын да киңәергә тора. Кичәгә чакырылган Венгрия, Кытай, Төркия, Үзбәкстан илчелеге вәкилләре бу эшкә бик теләп кушылырга булдылар. Хәер, ул башланган да инде. Венгрлар белән Татарстан галимнәренең бергәләп эшләгән хезмәте якын көннәрдә китап булып чыгарга тора. Кытай Республикасы территориясенә кергән Төркестан тарихын өйрәнү турында да сөйләшүләр бара.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Борчыган мәсьәлә

МӘКТӘП КӨТӘ, УКЫТУЧЫ КИТӘ

Татарстанда бер-бер артлы яңа мәктәпләр ачыла, әмма яшь кадрлар җитмәү мәсьәләсе һаман да актуаль кала бирә. Әлбәттә, укытучыга зур җаваплылык йөкләнә, яшь белгеч исә аны икеләтәөчләтә тоя.

Укучыны ничек кызыксындырырга, ата-аналарның ышанычын ничек яуларга, коллективка ничек ияләшергә, кәгазь эшен ничек дөрес алып барырга? Сораулар шактый. Моннан тыш, яшь белгечләрнең күбесе хезмәт хакы аз булудан зарлана. Ни өчен бүген яшь укытучы мәктәптә эшли алмый? Аларны ничек җәлеп итәргә?

Эшкә әзер түгел

Бүген яшьләрнең күбесе югары уку йортларына теләмичә бара. Йә аларны ата-аналары укырга үгетли, йә башка сәбәпләре була. Укытучы һөнәренә әйләнеп кайтсак, кайберәүләр педагогика институтына нинди дә булса һөнәргә ия булу өчен генә керә. Нәтиҗәдә, укып бетергәннән соң, яшь белгечләрнең аз өлеше генә мәгариф системасында кала. Моның сәбәпләрен студентлардан белештек.

– Минем магистратурага укырга кереп, тулы югары белем аласым килә. Әмма мәктәпкә эшкә барасы килми, чөнки мин моңа әзер түгел. Укытучы җилкәсендә җаваплылык зур, ә хезмәт хакы без теләгәннән әз, – ди укытучы һөнәрен үзләштерүче дүртенче курс студенты Рамилә.

Укытучы һөнәренең авырлыгы, тискәре яклары турында М.Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогика университеты көллиятен тәмамлаган Адилә Гыймаева да сөйләде.

– Мин балалар белән эшләргә ярата идем. Шуңа күрә башлангыч сыйныф укытучысы һөнәрен сайлап, уку дәвамында ярты ел буе мәктәптә эшләп карадым. Әмма бүген мин башка белгечлек буенча эшлим, чөнки укытучы һөнәренең тискәре яклары күп икәненә төшендем, – ди ул. – Әйтик, хезмәт хакы аз, буш вакыт та бөтенләй юк диярлек, укытучы якланмаган дигән хис тә калды. Сиңа көн-төн мәктәп җитәкчелеге, ата-ана белән элемтәдә булырга кирәк. Дөресен әйткәндә, шушы өлкәгә түккән көчнең 60 проценты укытуга, ә 40ы документлар белән эшкә китә.

Педагогика институтының бишенче курс студенты, узган ел мәктәптә эшли башлаган Диләрә (исеме үзгәртелде) дә үз тәҗрибәсе белән уртаклашты:

– Ярты ел эшләгәннән соң, китү теләге барлыкка килде: мәктәп зур, балалар күп. Яшь белгечләргә мөнәсәбәт яхшылардан түгел, укытучыны әллә ничә төрле кәгазь эше көтә, – диде студент. Аның фикеренчә, яшь белгеч гадәттә ярты йә бер елдан соң мәктәптән китә. Авырлыклар күп булса да, ул үзен барыбер мәгариф системасында күрә.

Алтынга тиң

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2010 елдан алып 2022 елга кадәр республикада 88 яңа мәктәп төзелгән, бу – 51 меңнән артык яңа урын дигән сүз. Ә яшь укытучыларга кытлык елдан-ел актуаль булып кала. Сүз уңаеннан, узган елның ноябрь аенда Казан мәктәпләрендә 35 яшькә кадәрге укытучылар саны 32 процентка җиткән иде.

Әмма Казанның мәгариф идарәсе башлыгы Ирек Ризванов әйтүенчә, педагогик кадрларга кытлык барыбер сакланган.

– Мәктәптә яшь кадрлар җитмәү, кызганыч ки, елдан-ел үзен сиздерә. Аеруча математика, физика, рус теле укытучылары җитми. Эш катлаулы, җаваплы. Яшьләр шуңа түзә алмый: өйгә кәгазь эше кайта,

Илдар Мөхәммәтҗанов

Укытучының белем дәрәҗәсе генә түгел, бала белән уртак тел таба белүе дә мөһим.

очы-кырые булмаган конкурслар да туйдыра, шәхси тормышка вакыт та калмый, – ди Түбән Каманың Бакый Урманче исемендәге 2 нче гимназия директоры Айгөл Гаязова. – Әлбәттә, тырнак, каш ясап, күбрәк акча эшләргә була, графигы да уңайлы, җаваплылык та юк диярлек. Без ел саен берәр яшь укытучыны эшкә алырга тырышабыз. Быел да яшь белгеч килде, башлангыч сыйныф укытучысы ул. Тулаем алганда, бүген өч яшь белгеч эшли. Кытлык дигәндә, безгә татар телен камил белүче укытучы кирәк, алар алтын бәясенә тиң.

Айгөл Гаязова әйтүенчә, ата-аналар балаларны тәҗрибәле укытучы укытуын тели.

– Яшь белгечләргә аһ итмиләр, чөнки барысына да тәҗрибәле укытучы кирәк. Кайвакыт үзләре дә кайчандыр яшь булганнарын оныталар, күрәсең. Әлбәттә, бөтенесе дә шундый дип әйтмим, арада төрлесе бар, – ди директор.

> Яшь белгечләргә хөкүмәт тарафыннан өстәмә түләү кирәк, дибез, әмма укытучы йөрәге «балалар» дип типмәсә, аны акча да, фатир да тотмый. Шуңа да карамастан, аларга уңайлы шартлар тудырсаң, яшь һөнәр остасы эшкә кереп китеп, мәктәпсез, балаларсыз яши алмый башлый.

Ата-ана таләбе

Чыннан да, күзәтү ясаганнан соң, яшь белгечләрнең мәктәптә озак эшли алмавына инанасың. Мисал өчен: Чаллының бер мәктәбенә узган ел биш яшь белгеч килгән иде, әмма ярты елдан соң икесе эштән китәргә карар кылган. Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2022–2023 нче уку елында мәгариф системасына 900дән артык педагог килгән. Шул ук вакытта 240лап яшь укытучы эштән киткән. Димәк, белгечләрнең якынча 27 проценты мәктәптә эшли алмаган.

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының Экспертлар советы әгъзасы Рәсимә Шәмсетдинова әйтүенчә, яшь белгечләргә укытучы булыр өчен тормыш тәҗрибәсе җитеп бетми.

– Яшь кадрлар мәсьәләсе бик кискен тора дип әйтә алмыйм, әмма башлангыч сыйныф укытучылары, чыннан да, җитми. Әйтергә кирәк, мәктәптә бер-ике атна эшләгәч, бу минем һөнәрем түгел дип, авырлыктан куркып киткән яшь укытучылар күп. Аларның ата-аналар белән сөйләшер өчен тормыш тәҗрибәсе юк, – ди ул.

Диана КАРПОВА, КФУ студенты

СУ ЮЛЛАРЫ ЛАЕШКА ИЛТӘ

ТАТАРСТАНДА ТӨЗЕЛӘЧӘК ЯҢА ОБЪЕКТ ТУРИСТЛАР САНЫН АРТТЫРЫРГА БУЛЫШАЧАК

Яхталар тукталышы 300ләп урынга исәпләнгән. Су өстендәге йорт, искиткеч манзара ачылган отель, пляж, спа-комплекс ише инфраструктура объектлары да каралган.

Туризм

Казаннан яхталы туризм башкаласы ясамакчылар. Һәрхәлдә, шуңа өметләнәләр. Лаешта төзеләчәк «Казан маринасы»* курорты шушы өметләрне акларга ярдәм итәргә тиеш. Бу эш белән шөгыльләнәчәк инвесторны да тапканнар инде.

Яңа туристик нокта

Татарстанның Лаеш районында яхта маринасын төзү белән Санкт-Петербург инвесторы шөгыльләнәчәк. Яңа туристик зона проектын Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановка кабат күрсәттеләр. Инвесторлар беренче тапкыр килгәндә нәрсәнең ничек буласын сөйләсә, бу юлы инде хезмәттәшләр буларак кул кысышканнар.

– Бу проектны эчке туризмны үстерүгә юнәлтелгән эш дип саныйбыз. Безнең республикада искиткеч климат, кунакчыллык инфраструктурасы үсеш алган. «Казан маринасы» проектын гамәлгә ашыру Татарстанга туристлар агымын тагын да арттырырга ярдәм итәчәк, – диде Татарстан Рәисе очрашуда.

Туристлар артуын Туризм.РФ корпорациясе дә көтә. Әйтүләренә караганда, «Казан маринасы» курорты «Бөек Идел юлы» төбәкара туристик маршрутының үзәге булып торачак. Димәк, Лаештагы курорт бөтен Идел буе округы кунакларын җәлеп итәргә тиеш.

Чәчәккә тиң

Курорт проектын берничә өлешкә бүлеп (9 лот), һәрберсенә инвестор табарга ниятлиләр. Беренчесе инде табылган, дидек. Ул – «Санкт-Петербург яхт-клубы» генераль директоры Владимир Любомиров. Яхталар өчен причал, аңа бәйле инфраструктура объектларын төзү белән нәкъ менә Төньяк башкала инвесторы шөгыльләнәчәк.

– Марина – өстәлдәге матур чәчәк бәйләме кебек. Ул аерым игътибар таләп итә. Безнең тәҗрибәбез бар. Санкт-Петербургта моңа охшаш мариналар төзегәнебез булды. Кара диңгездә эш алып барабыз. Россиядәге акватория – диңгезләр түгел, елгалар ул. Минемчә, Казан елга буенча яхта туризмы башкаласы булачак, – диде кунак журналистлар белән очрашуда.

Әйтүенә караганда, проект эше киләсе елда тәгәлләнсә, ел азагына инде төзелеш эшләрен дә башлап җибәрергә мөмкин. 2027 елга исә курортны тулы көченә эшләтеп җибәрергә телиләр.

Татарстанның Туризм буенча дәүләт комитеты җитәкчесе Сергей Иванов искәрткәнчә, курорт кысасында 1250 кунакханә номеры ачарга, 2 меңләп яңа эш урыны булдырырга җыеналар. Инвестицияләр күләме дә саллы – 18 млрд сум. Әлеге проект тормышка ашырылу нәтиҗәсендә 2030 елга Лаешка килүче туристлар саны 620 меңнән артып китәр, дип өметләнәләр. Курорт ел әйләнәсе эшләячәк.

Проектка акча кертергә теләгән инвесторлар санын төгәл әйтмәсәләр дә, уннан күбрәк, дип белдерделәр. Санкт-Петербург кунагы тугыз инвестиция лотының бишенчесенә алынуын әйтте.

– Бишенче лот үз эченә яхта маринасын, кунакханә, променадны ала. Болар – нәкъ без эшли белгән нәрсәләр. Инвестицияләр күләме якынча 1,5–2 млрд сумга җитә, – диде Владимир Любомиров. – Мин бу урыннарга гашыйк. Мин аларны шәхсән карап чыктым. Казанда инвесторларга карата булган мохиткә дә гаҗәпләнерлек. Сездә безнең кебекләр белән эшли беләләр һәм бу күңелгә рәхәтлек бирә.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

* Марина – яхталар өчен махсус җиһазландырылган тукталыш урыны, анда экипажга төрле хезмәтләр күрсәтелә.

Сәхнә яшәртә

«БАЛКЫШ» ФЕСТИВАЛЕНДӘ 100 МЕҢНӘН АРТЫК КЕШЕ КАТНАШКАН

Моңаеп утырмасыннар. Татарстанда «Балкыш» республика фестиваленең сигезенчесенә әзерләнәләр. Ветераннар арасында узучы әлеге чарага район һәм шәһәрдәге талантларны мартта барлый башлыйлар. Дәүләт Советында Җиңүнең 79 еллыгына багышланачак фестивальнең оештыру комитеты утырышы узды.

Татарстанның Дәүләт Советы Рәисе, оештыру комитеты рәисе Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, «Балкыш» фестивале – өлкәннәр арасында үткәрелүче иң зур иҗади проект.

– Фестиваль республикабызның мәдәни тормышында үз урынын тапты. Мондый чаралар өлкәннәрнең иҗади сәләтләрен үстерүгә һәм ялын оештыруга ярдәм итә, – диде парламент башлыгы.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, җирле хакимият, министрлык һәм оешма җитәкчеләре ярдәме белән узучы фестивальдә катнашучылар ел саен арта бара. Татарстан ветераннарының (пенсионерларының) төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе Хәбир Иштирәков әйтүенчә, 2012 елда беренче фестивальдә 3,5 меңгә якын ветеран катнашкан булса, җиденче «Балкыш» фестивале үзенең концерт мәйданчыкларында 20 меңнән артык башкаручыны җыйган. Зона чыгышларында 3300 кеше катнашкан. Республикакүләм жюри барлыгы 530дан артык номерны караган. 312 чыгыш жюри тарафыннан лауреатлар буларак билгеләп үтелгән. Узган ел фестиваль лауреатларының 4 гала-концерты узды. Гомумән алганда, җиде фестивальдә 100 меңнән артык кеше катнашты.

– Узган ел фестивальдә Аксубай, Алексеевск, Арча, Әтнә, Балтач, Бөгелмә, Буа, Биектау, Алабуга, Кукмара, Мамадыш, Минзәлә, Мөслим, Түбән Кама, Балык Бистәсе, Саба, Спас, Тукай, Чистай районнары, шулай ук Казан һәм Чаллы шәһәрләре актив катнашты. Фестивальдә катнашмаган бер генә район да юк. Башта районнарда сайлап алу чыгышлары булачак. Март – апрель айларында Казан, Чаллы Кукмара, Әлмәт, Буа, Арча, Алексеевскида зона этаплары узачак. Ике гала-концерт оештырырга ниятлибез. Беренчесе – Җиңү көненә багышлап, май аенда, икенчесе октябрьдә булачак. Анысы өлкәннәр декадасына багышлап, Җиңүнең 80 еллыгына әзерлек кысасында узачак, – диде Хәбир Иштирәков.

Өлкәннәр яшерми – бу фестиваль аларны яшәртә, яшьлегенә алып кайта, олы сәхнәгә чыгара. «Балкыш»та табылган талантлар хәзер төрле концертларда катнаша, үз районының данын яклый.

– Мине дә катнаштырыгыз, дип эш урыныма да киләләр. Һәркемнең чыгыш ясыйсы килә. Искитмәле табышлы кешеләр күп, – ди Хәбир Иштирәков. – Араларында элеккеге сыер савучылар, тракторчылар, мал караучылар бар. Кайчандыр алар сәхнәне түгел, авыл хуҗалыгын сайлаган. Хәзер менә сәхнә аларны чакырып тора. Катнашучыларны мәртәбәле жюри сайлап ала. Теләге булган һәркемне фестивальдә катнашырга чакырабыз.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

БЕР ТАМЫРДАН ҮСКӘН ГӨЛЛӘР

Соклану

Кырык елга якын гомерен мәгариф системасына багышлаган Резидә Гаязова үткән гасырның туксанынчы елларыннан башлап бүгенгәчә Балтач районы мәгариф династияләрен ачыклый, мәгълүмат туплый.

Династияләр турында сүз чыкканда, ул еш кына «бер тамырдан үскән гөлләр» дигән бик матур чагыштыру китерә.

– Чыннан да, алар бит бер тамырдан үскән гөлләр кебек – бер нәсел балалары, дәвамчылары, – ди ул үзе, бу хакта сорагач. – Шөкер, күпьеллык хезмәтем юкка чыкмады, хәзерге көндә районыбызда 37 педагогик династия ачыкланды. Мәчетләр каршында, үз йортларында балаларга дини белем биргән мулла-остазбикәләрдән башланган бу шәҗәрәләрдә дүрт буын укытучы-тәрбиячеләр күп. Бишенче буын укытучылар бар. Бик күләмле – 200 биттән артык зур исемлек бу.

Тормышта бер генә нәрсә дә, бер генә эш тә сәбәпсез, тиктомалдан башланмый. Тынгысыз, шул ук вакытта бик тә төгәл (икенче белеме буенча икътисадчы) Резидәгә бер чорда район мәгарифенең төрле тармаклары, пионер, комсомол оешмалары, мәктәпләр-авыллар тарихын өйрәнүчеләр документлар сорап мөрәҗәгать итә. Төрле очрашуларны, өлкәннәрнең истәлекләрен туплап барган язмам героена тарихи хатирәләрен язмача китерүчеләр дә шактый була. Сакланган документлар белән бергә әнә шул истәлекләрне дә теләп уртаклаша Резидә. Алар инде төрле форматта тарихи китапларда урын алган. Кул астында булган бөтен мәгълүматларны тарих язучыларга биргән вакытта үзе дә династияләрнең күплегенә игътибар итә, кызыксынып, алар турындагы һәр хәбәрне бөртекләп җыйный башлый ул. Һәм еллар үткән саен, аларны тулыландыра гына.

37 династия арасында гомуми стажлары бер гасырдан да ким булучылар юк. Династия дибез икән, анда кимендә өч буын булырга тиеш дип саный Резидә. Шундый таләпкә туры килүче 200–300 еллылар шактый. Әйтик, Мөэминоваларның гомуми стажы – 696 ел, Медведевларның – 668, Егоровларның – 612, Сөләймановларның – 590…

Әнисе Бәдәр исеме белән башланган Мөэминовлар династиясеннән дә бүген район мәктәп-бакчаларында 14 кеше хезмәт куя.

– Мин шушы нәселнең бер тармагы булуым белән бик бәхетле һәм горурланам, – дип дәвам итә язмам герое. – Әнием Бәдәр 1919 елны Балтач авылында күпбалалы, урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. Шул чорда җиде сыйныф белем алучы сирәк кешеләрнең берсе була ул. 5–6 сыйныфларны ул, һәр көнне бер якка 8 километр араны җәяүләп йөреп, Карадуган мәктәбендә укыган. Балтачта ТБУМ ачылгач, җиденче сыйныфны шунда кайтып тәмамлаган. Сәләтен күреп, аны укытучы итеп эшкә чакыралар. Башта бер айлык укытучылар әзерләү курсларында, аннан Арча педагогик училищесында белем ала. Әтнә, Яңа Салавыч, Сосна мәктәбендә балаларга белем бирә. Әниемнең ике сеңлесе дә – укытучы. Физика һәм математика фәннәреннән укытучы Гадения апабыз «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнә. Мөэмин (тулы исеме – Габделмөэмин) бабабызның алдынгы фикерле булуында һич шик юк. Шушы нәселдән 31 кешенең укытучы, тәрбияче һөнәрен сайлавы күпне сөйли. Нәселебез горурлыгы булган Мәгъмүрә апабыз Гафарова (Рамазанова) – кантон чорында ук укытучылык эшен башлап, моңа кадәр дини белем генә бирелгән мәктәпләрдә яңача укытуны башлаган, беренче пионер отрядлары оештырган кеше. 100 яшькә җитеп, гомеренең соңгы көненә кадәр зирәк зиһене, камил акылы белән күпләрне сокландырды. Хезмәтләре өчен Татарстан АССР Югары Советының Мактау грамотасы белән бүләкләнә, илебезнең иң югары бүләге – Ленин орденына лаек була. Татарстанның атказанган укытучысы, ике чакырылыш Татарстан АССР Югары Советы депутаты. Тормыш иптәше Фәйзрахман белән бергә алар Балтачта мәктәп төзелеше өчен үз бакчаларыннан 30 сутый җир дә бүлеп бирә. Шушы гаиләдә үскән балалар да укытучылык хезмәтендә зур уңышларга ирешә. Хәзерге көндә Балтачта яшәүче Клара апабыз шулай ук «Татарстанның атказанган укытучысы» исеменә лаек була, РСФСРның халык мәгарифе отличнигы. Иң сөендергәне: Мәгъмүрә апа, әниебез Бәдәр башлаган укытучы һөнәрен бүген онықлары-оныкчыклары лаеклы дәвам итә.

Сүз уңаеннан, Балтач – беренчеләрдән булып укытучыга һәйкәл куйган район да.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Авыл җаны

«Хәзер авыл кешесе культурныйрак»

Рәдинә апа белән танышып китүемә «Әтнә таңы» сәбәпче булды. Минем әнием – Әтнә ягыннан, аның истәлекләрен район газетасына җибәргән идем; андагы туганнар белән аралар өзелеп бара, безнең нәсел-нәсәп турында белүчеләр булса, хәбәргә чыгыгыз әле, дип үтенечемне дә белдергән идем. Рәдинә апа бабам ягыннан дүртенче буын туганыбыз булып чыкты. Бу аның өчен дә, минем өчен дә бик сөенечле һәм көтелмәгән яңалык иде.

«Мин шәһәрне элек тә яратмадым, әле дә яратмыйм. Андагы угы-чугыны яратмаганга, аласы әйберемне дә алмыйча, ашыгып кайтып киткәнем бар. Тынычлыкны яратам», – диде ул, авылда калуының сәбәбен аңлатып.

Бүгенге авыл әле дә әүвәлгечә матур дип саный ул. «Безнең якларда авыл кешесе шәһәр кешесеннән аерылып тора: бер-береңә ярдәм итү, аралашып яшәү, элеккеге кадәр үк булмаса да, әле дә бар. Хәзер авыл кешесе культурныйрак. Элек фермага, мәсәлән, эш киеменнән, резин итекләрне лыштырдатып бара иделәр, хәзер матур киенеп баралар да киемне эш урынында алмаштыралар», – ди.

Әйе шул, прогресс ике яклы: бердән, эшне җиңеләйтә, икенчедән, эш урынын азайта. Рәдинә апа да ачык күрә моны: колхозда гомер буе бухгалтер, экономист булып эшләгән кеше. Әле дә авыл тормышының бар ягыннан хәбәрдар.

– Авылда әлегә балалар бакчасы бар, урта мәктәп бар (башка авыллардан да киләләр), почта, медпункт, авыл советы бар. Аларда үзебезнең авыл кешеләре эшли. Эшләрлек кеше 324 булып, шуның 54е – колхозчы, 51е – интеллигент, читкә 188 кеше китеп эшли. Эшнең бары-югы шуннан күренә инде. Хәзер ындыр табагы, машина-трактор паркы юк, ферманың ике торагы гына утырып тора, анда терлек юк; элек күп кеше шунда иде. Үзәкләштерелгәч, алар Әтнәгә күчте. Үзебез әүвәлгечә «колхоз» дибез инде, ООО аталса да. Безгә инвестор кермәде, эшләр әүвәлгечә алып барыла. Тукай хуҗалыгына керәбез, 54 колхозчы Әтнәгә йөреп эшли, аларны автобус йөртә. Фермада эшләр механикалаштырылып бетерелгәч, анда эшләргә кеше күп кирәкми дә хәзер.

Элек мичкә күмерне ягып, суны көянтә-чиләк белән китерә идек – бөтенесе кул белән эшләнә иде. Хәзер шәһәр йортларына җылы биргәнче, без инде җылыга тиенәбез. Җылы су да, салкыны да бар, су чыгып китә, түгеп азапланасы юк. «Чиста су» программасы белән барлык өйләргә дә су кертелде, авылда колонка юк инде хәзер.

Тагын бер нәрсәгә игътибар итә ул: кеше ялкауланды, ди. «Элек ял бик булмады инде, күрше-тирәгә кереп кич утырулар була иде, шул гына. Элек бездә плотинаны бар дип белгән кеше дә юк иде, хәзер шунда менеп, балык тотып утыручылар, шашлык пешереп ял итүчеләр күбәйде», – ди.

Хәзерге балаларга эш булмауга да борчыла. «Эшсез бала ул – йә урамда, йә телефонда». Хезмәт белән нығып үскән бала максатчанрак, тырышрак, тәрбиялерәк – бу, чыннан да, бәхәссез. Моны күп кенә ата-аналар да аңлый; балаларын төрле түгәрәкләргә, секцияләргә йөртә; тәртипкә, режимга өйрәтергә тырыша.

Хәер, тагын бер уртак борчу бар икән әле. «Без урыс күреп үсмәдек, хәзер исә урамда балаларның чын урыс кебек сөйләшкәнен ишетеп ушың китәрлек. Телефоннан мультфильмнар, төрле кызык-мызык карап, татарлыктан китеп бара балалар. Балалар бакчасы да, мәктәп тә телне, гореф-гадәтләрне саклауда нык тырыша үзе, ләкин шулай да замана белән бергә бара инде ул тормыш… Бик борчый менә шул хәл. Татар теленең грамматикасын хәзер олыларның да күбесе белми. Шигырьләр, җырлар язып йөрүчеләр арасында да да-дә, та-тә кисәкчәләрен аера белмәүчеләр күп…»

Рәдинә апа – лаеклы ялда. Кайберәүләр кебек, көнен ничек үткәрергә белмичә азапланмый. Көн җитми дә, ди. «Яшь вакыттагы шикелле бик кызу эшләп булмый хәзер, үз көеңчә эшлисең. Беренче класста Әлифбаны укып бетергәндә, мин инде шәл чите бәйләргә өйрәндем. Гомер буе шәл бәйләдек, әти-әниләрнең эшләгән акчасына гына тормыш алып барып булыр шикелле түгел иде. Каз саклый идекме, бәби карый идекме – безнең кесәдә җеп, кулда шәл чите була торган иде. Хәзер бәйләүнең төрлесен яратам, интернетта күргән, кызыксындырган бөтен нәрсәне эшләп карыйсы килә». Өйләрендә картиналарның нинди генә техника белән эшләнгәне юк аларның, чиккән, бәйләгән, теккән уенчыклар дисеңме, үз куллары белән үргән кәрзиннәргә кадәр бар! Ишегалды турында аерым язарга кирәк: дизайнерларча ясалган күлләр, таулар, чәчәкләр-гөлләр, каз-үрдәкләр белән бизәп эшләнгән ул. Бу эшләрдә Әтнәдә яшәүче кызы белән кияве дә, Казанда яшәүче улы белән килене дә булыша. Аерым тәм белән җиләк, гөмбә җыялар алар, балык тоталар…

Шундый кешеләр була: аларны тыңлаган саен тыңлыйсы килә, ардырмый; алардагы яшәүгә мәхәббәт сине дә үз дулкынына алып кереп китә; дөньяның матур һәм киң икәнлеген исеңә төшерә. Рәдинә апаларда җәй көне кунакта булып, данлыклы Калатауны, Күлле Кимедә Сибгат Хәким музеен, Әтнә, Дусым, Күәм Сабан туйларын күреп, биредәге гаҗәеп матур табигать белән хозурланып кайткач, мин дөньямның күпкә тулыланып китүен аңладым. Тормышны менә шундый кызыксынучан кешеләр тотып тора да инде ул. Алар сиңа яшәүнең никадәр кызык сәяхәт булуын аңлата.

Лилия ФӘТТАХОВА



Илдар Мөхәммәтҗанов

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Еракка китеп кара

Әйбәт кеше белән алама кешене ничек аерырга? Гади генә. Әйбәт кешеләр безнең әйбәт якларны күрә, начар кешеләр – начар сыйфатларны.

Кечкенәдән бергә аралашып үскән бик якын бер дустым бар. Әйбәт малай инде ул. Тынгысыз, эшчән, якты күңелле. Туры сүзле. Туры сүзле булуы минем өчен бик үк җайлы да түгел бугай, чөнки ул авыр кабул ителә. Син салпы ягыңа салам кыстыруны көтәсең, ә ул ачы дөреслекне ярып сала. Һәм иң аянычлысы аның хаклы икәнен аңлау була. Ну, әйтик, әсәрен укып чык та кешенең: «О, әйбәт!» – дигән бул бит инде. Юк! Бу алай дими. Ерунда, ди. Моның ишене генә мин дә маташтыра алыр идем, дип тә өстәп куя. Җан убылып китә инде шунда. Язганыңны тагын бер кат карап чыгасың. Шайтан алгыры! Ул бит хаклы. Аның хаклы икәнен аңлаудан бигрәк, үзеңнең шундый пүчтәк нәрсә эшләвеңне үзең дә тоймау була. Аның туры сүзлелеге авыр минем өчен. Ләкин ул мине әйбәтрәк итә. Җайлы кеше булу белән әйбәт кеше булуның да аермасы бар шул…

Менә шул егет күптән түгел генә хатыныннан аерылды. Бозылышып, сөйрәлешеп йөрделәр-йөрделәр дә соңгы чиктә аерылышып туктадылар. Хатыныннан аерылышу сәбәбен сорагач, ул бер сүз белән генә җавап бирде:

– Эчә бит ул…

Бу минем өчен артык зур яңалык булмады. Ләкин тел очында очкын уйнатып торган сораудан котылып кала алмадым:

– Кем эчми соң?

Ул иңнәрен генә кагып куйды. Сүз балалатып тормадым. Бары тик уйларыма гына биреледем.

Бер гаиләне искә төшердем. Ире бик нык эчә инде моның, хатыны да кимен куймый бугай. Балалары салкын күлләвектә аунап үстеләр. Ачлы-туклы булып. Үз улларым да шулар яшендә булгач, мин аларны бик кызгана идем. Үткән-сүткәндә кибеттән тәмлүшкәләр алып бирәм, кайчагында мунча кертеп тә чыгарам, вак-төяк белән ярдәм итәргә тырышам. Һәм һәрвакыт гаҗәпләнә идем: безнең балалар чирләп ятканда алар төчкереп тә карамый. Нык булып үстеләр. Тормышта үз юлларын таптылар, матур гына яшәп яталар. Очрашканда кочаклап алалар: «Марат абый, безне син үстердең бит…» – дигән булалар. Бәлки, мин чынлап та балачакларының берәр бизәге булып тоелганмындыр, ләкин аларны мин үстермәдем инде. Үзләре үсте. Әти-әниләре дә айныды, абруйлы гына кешеләргә әйләнделәр. Балалары да алар дип өзелеп тора, үзләре дә инде, билгеле. Бәлки, бу могҗизаның берәр төредер инде. Тик мин гел халык сүзен искә төшерәм. Исерек айный ул, ахмакка акыл керми.

Теге дустым да беткәнбаш егет түгел. Без аның белән телефон аша да, болай да еш аралашабыз. Төрле темаларга сөйләшәбез. Платон белән Диоген да, Аристотель дә калмый. Буддизм, даосизм, ислам тирәләрен дә айкап чыгабыз. Эзотерикага кереп, Блаватскаяларны да болгатабыз. Ницше белән Зигмунд Фрейд та әллә ничә тапкыр әйләнеп ята. Фәлсәфә, дин, психология гына түгел, әдәбият дөньяларын да әйләнеп чыгабыз. Көнбатыш язучыларын, Көнчыгышныкыларны. Классикларны, бүгенгеләрне. Кайчагында ул мине: «Эльмира Җәлилованың, Гөлнара Сабированың яки Гөлүсә Батталованың фәлән-фәлән шигырен укыдыңмы?» – дип тә аптырата. Үз әсәрләрем буенча да югалып калырлык сораулар биреп куя. Мин гомерем буена «зыялылар» дип аталган кавем арасында яшәгән кеше бит инде. Ләкин алар арасында да бу дәрәҗәдә төрле темаларны айкарлык кешеләрем сирәк. Ркаил Зәйдулла бар. Илфак Шиһапов бар иде. Әдәбият энциклопедиясе кебек Рәдиф Гаташ бар. Озаграк уйлап торсаң, тагын берничә шәхесне искә төшерергә мөмкиндер. Ләкин алар – зыялылар. Ә бу егет бит – гади авыл малае. Тракторчы, шофер, сатучы.

Шуңадыр инде хатынының сүзе миңа аз гына сәеррәк ишетелде. Кечкенәдән таныш булсак та, мин аның беркайчан да чайкалып йөргәнен, теленә ни килә, шуны лыгырдап, кәеф кайтарганын күргәнем юк. Хатыны күрәдер инде. Ул бит гел якында. Ләкин якыннарыңа да кайвакыт ерактанрак карарга кирәктер. Зур нәрсәләрне күрү өчен ераклык таләп ителә. Шәхесләрне дә шулай.

Яраткан кешеңнең әйбәт якларын гына күрәсең, күзеңә бәрелеп торган гариплекләрен дә камиллек дип кабул итәсең. Ә ярату сүнгәч, яратмавың өчен аклану эзләп, гаепләрен табарга тырышасың. Яратмавың өчен акланырга кирәкмидер, бәлки. Хис бит инде ул. Ялкын кебек. Дөртләп кабынырга да, гөлтләп сүнәргә дә мөмкин. Мәхәббәтнең дә – үз гомере. «Нигә иртә үлдең?» – дип, кешеләрне гаепләп булмаган шикелле, мәхәббәтне дә аз гомерле булуы өчен гаепләргә кирәкмидер. Һәркем бәхеткә хаклы. Аңа кемнәрдер парлашып, кемнәрдер аерым-аерым килә.

Әле менә уйлап утырам. Ул дустымның ике экскаваторы, ике йөк машинасы, ике җиңел машинасы бар. Хатыны белән бергә корган дөньялары әйләнеп чыккысыз. Хәзер үз куышын корып ята. Үзем белән чагыштырып карыйм… Миндә боларның берсе дә юк… Экскаваторлар да, йөк тартучы һәм җиңел машиналар да… Йорт-җирем дә артык зурдан түгел… Югыйсә бик күп эшләдем бит инде бу дөньяда. Барысы да булырга тиеш кебек иде…

Шәхесләребез

НУРИХАНГА КАЙТУ

Ул яши. Ул яшәр! Фани дөнья белән шактый еллар элек хушлашса да, халык хәтерендә ул әле дә яши, күпләрнең күңел күгендә юл күрсәтүче йолдыз булып яна. Исән булса, быел татар әдәбиятында тарихи роман жанрына нигез салган мәшһүр әдип, Тукай исемендәге Дәүләт премиясе иясе Нурихан ага Фәттахка 95 яшь тулган булыр иде. Туган көнендә без аны зал тулы халык белән бергәләп искә алдык.

Коллажда «Татар-информ» фотосы файдаланылды

Нурихан Фәттахны искә алу кичәсе башкаладагы Тукай музеенда узды. Режиссер Александр Далматов әзерләгән әдәби-музыкаль чара «Нурихан Фәттах Казаны» дип аталган пластик-музыкаль композиция белән башланды. Студентлар сүзсез, бары хәрәкәтләр белән генә әдипнең Казанда татар теле хакына алып барган көрәшен күрсәтте. Аның ни дәрәҗәдә үҗәт, үзсүзле булуын, үсмер чагыннан ук системага каршы баруын «Кичү» романыннан күрсәтелгән өзекләр тасвирлады. Үз тормышы турындагы бу әсәрен ул «чынбарлыкны әз генә дә бозмыйча, бизәмичә, һәрнәрсәдә – аеруча халык тормышын һәм милли мөнәсәбәтләрне тасвирлаганда – дөреслекне ярып салыр» өчен язган. Өзекләрне студент эскәмиясендәге яшьләр күрсәтүе сөендерде, билгеле. Тел, милләт турындагы монологларны ятлаганда, күңелләре җилкенгән булса ярар иде…

Кичәдә Нурихан Фәттахка карата ихтирам сүзләре дә, аңа бәйле истәлекләр дә күп яңгырады. Казан Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Гүзәл Сәгыйтова үсмер чагын искә алды:

– Иң яхшы тарихи әсәрләр авторларын иң яхшы тарих укытучыларына юкка гына тиңләмиләрдер. Нурихан аганың киңкырлы иҗатын барлаганда шул сүзләр искә төшә. Үсмер чакта ул безне гаять катлаулы, әмма гаҗәеп кызыклы дөньяга җитәкләп алып керде. Моның өчен рәхмәт аңа! Нурихан аганың иҗат энергиясе, импульсы шулкадәр көчле булган ки, хәтта оныкларына да җиткән. Киявенең (оныгы Зөләйха Камалованың тормыш иптәше Руслан Ибраһим. – **Авт.**) рәссам булуы да очраклы түгелдер. Нурихан ага да рәсем белән мавыккан, хәтта рәссам булырга теләгән бит, – диде ул.

Оныгы, димәктән. Зөләйха Камалова белән без дә аралаштык. Бабасы аңа ничек тәэсир итте икән?

– Беренче чиратта ул миңа кеше буларак бик нык тәэсир итте. Язучыдан бигрәк, бабам буларак белдем бит инде мин аны. Ә әдәбиятка карата булган кызыксынуыма күпмедер дәрәҗәдә генетиканың тәэсире булгандыр дип уйлыйм. Үсмерлек чорын узып, язучы буларак өйрәнә башлаганнан бирле картәтәйне яңа яктан ачам. Ә бит әле аны ачасы да ачасы…

Бабасына бәйле булган һәм хәтерендә калган бер вакыйганы да искә алды Зөләйха.

– Ул көне буе эшләде – без үзебезгә үзебез тапшырылган идек. Кечкенә булсак та, абыем белән икебезгә балта-чүкеч тотарга өйрәтте ул. Шулай берсендә утын китерделәр дә без утын ярырга тотындык. Картәтәй туз яндыруның рәтен дә өйрәткән иде. Шуны искә төшереп, утын ярган җирдән, туз яндырып карарга булдык… Ярый ла инде ул эшли торган кабинетның тәрәзәсе ягында идек. Йөгереп чыгып, аягы белән утны сүндерергә тотынды. Бик кырыс кына итеп башка алай эшләргә ярамаганны аңлатты. Һәм без башка алай эшләмәдек тә… Иҗатта да, гаиләдә дә сүзен кистереп әйтә белде ул.

Татарстанның халык язучысы Рабит Батулла үз китабыннан Нурихан Фәттахка бәйле бер өзек укыды.

– Нурихан Фәттах, Солтан Шәмси белән Марсель Галиев янына килгән дә: «Һай, шулай булсачы», – ди икән. «Ник алай дисең?» – дип сораган егетләр. «Сезнең икегезне бергә кушсаң, Солтан-Галиев килеп чыга икән. Ләкин ниләр генә кылансаң да, татарда кабат Солтан-Галиев булмаячак. Кызганыч, Солтаннар бар, Галиләр бар, Гаязлар бар, Исхакыйлар бар, әмма Солтан-Галиевләр, Исхакыйлар әле күренми», – дип җавап биргән Нурихан.

«Нурихан абый, язучылар съездына килгәндә, ничек тә юлын табып, мөнбәргә чыга иде һәм хөкүмәткә бер «типмичә», бер төрттермичә калмый иде. Без, яшьләр, аны исебез китеп тыңлый идек». Язучы Вахит Имамов Нурихан Фәттахка бәйле истәлекләрен яңартты:

– Әле съезддан чыгып китеп, тагын бер-ике җөмләсен тыңлар өчен, артыннан ияреп йөри идек. Аның белән әңгәмә кору әйтеп бетергесез рәхәт иде. Миңа аның туган авылында булу бәхете дә тәтеде.

> «Мөдир Саҗидә» әсәре өчен гонорар алганнан соң, кайтып, әнисенә һәм әнисенең апасына йорт салган булган ул. Алар анда 20 еллап яшәгән.

Нурихан Фәттах, бөтен галимнәрдән дә уздырып, ике мең еллар элек Азия якларында яшәгән татарлар язмышын күтәреп чыкты. Ул күтәргән темаларны тарихка кайтару өчен ничә йөз ел кирәк икән?..

Шунысы өчен йөрәк сыкрый: әле дә Нурихан аганың музее юк. Тормыш иптәше Руфина апа тырышлыгы беләндер инде, узган ел Яңавылдагы яңа урамнарның берсенә аның исемен бирделәр бирүен. Анда да алай зурлап искә алынганы юк иде…

Россия һәм Татарстанның халык артисты Равил Шәрәфиев сүзен шәхес һәм бу сүзнең дәрәҗәсе турындагы уйланулардан башлады.

– Бу кичәдә «шәхес» сүзе еш телгә алынды. Дөресен генә әйткәндә, мин ул сүзне еш куллануларына каршы. Хәзер бит чыгалар да бер нәрсә эшләмәгән кешегә дә, җырлый белми торган җырчыга да – барысына да «шәхес» диләр. Ә Нурихан Фәттах – шәхес дисәң, шәхес! Беркайчан беркемгә буйсынмады, үз юлы белән барды, шул юлга тугры булды. Менә кем ул шәхес! Мин Нурихан абыйның күзләрен ярата идем. Аныкы кебек күзләрне бер-ике кешедә генә күргәнем булды. Анда еракта янган йолдызларның барысы җыелган иде. Сиңа караса, үтәли күрә белде. Тарихны да шулай күрде Нурихан абый. Ул яши. Ул яшәр! – диде ул.

Нурихан Фәттахны искә алган көнне Тукай музеендагы залда алма төшәрлек кенә урын бар иде. Чордашлары, Нурихан аганы күреп калган әдипләр белән бер рәттә яшьләр утырды – алар да аңа ихтирам белдерде.

– Бүген чыгыш ясаган әдипләрдән аермалы буларак, минем Нурихан аганы тереләй түгел, хәтта телевизордан да күргәнем булмаган, – диде шагыйрь Рүзәл Мөхәммәтшин. – Шуңа да карамастан, ул гомер буе минем белән булды. Узган гасырның буталчык 90 нчы елларында, тарихны ничек укытырга белмичә аптыраган, «Без кем?» соравына җавап бирә алмый торган укытучылар укытканда, кулыма Нурихан аганың китаплары килеп эләкте. Һәм мин сорауларыма җавап таба алдым. Моның өчен аңа зур рәхмәт. Вакытында безнең әтиләр дә, нәкъ минем кебек, бөек халыкның бер вәкиле булуларына шулай инангандыр. Нурихан аганың алдан күрүчәнлеге бәрабәренәдер инде. Минем улым да бүген чын тарихны аның әсәрләре аша өйрәнә, төрле яктан җилләр искәндә, аякта нык торыр өчен, аның китапларына мөрәҗәгать итә.

…Чара барышында да, аннан соң да, Нурихан ага кебек киңкырлы шәхескә киңрәк зал кирәк иде, дигән фикерләр күп яңгырады. Хәер, нинди генә мәйдан бирелсә дә, Нурихан ага шәхесе, иҗаты, аның гыйлеме аңа сыеша алмас иде. Аннан әле өйрәнәсе дә өйрәнәсе…

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Үзебезгә кайтабыз

Язучы Нурихан Фәттахка

Утыртмадылар түрләргә,
Чөймәделәр күкләргә…
Аның телле-тешле сүзе
Ошамады күпләргә.

Без гөр килеп кул чапканда,
Карап торды аптырап…
Шуңа бүген аның йөзе
Безнекеннән яктырак.

Без Казанда балкыганда,
Ул шәм якты Чыңгызда.
Без табындык – күкрәктәге,
Ул – күктәге йолдызга.

Ул барасы юл читендә
Маяклар кабынмаган.
Анда әле Болгар исән,
Казан да алынмаган.

Анда әле безнең тарих
Көл белән күмелмәгән.
Анда әле минем телем
Кырыкка бүленмәгән.

Тигез анда бар милләтләр,
Уртак анда киң җиһан…
Шушы хөррият илендә
Патша икән Нурихан.

Кем килмәде, кем китмәде,
Кем булмады атабыз?!
Менә бүген без яңадан
Хөр мәмләкәт ханлыгына
Нуриханга кайтабыз!

Разил ВӘЛИЕВ

САГЫШ ЙОРТЫ

ТИНЧУРИН ТЕАТРЫ 90 НЧЫ СЕЗОННЫҢ БЕРЕНЧЕ ПРЕМЬЕРАСЫН ТӘКЪДИМ ИТТЕ

tinchurinteatr.ru

Сәхнә

Гомер көзенә кергәндә кем генә үз туган нигезендә, якыннары янында тынычлыкта һәм муллыкта яшәргә хыялланмый икән? Тинчурин театры 90 нчы юбилей сезонының беренче премьерасы – картлар йортында яшәүчеләр турында «Ай, былбылым!» моңсу комедиясен тәкъдим итте. Шамил Фәрхетдинов әсәрен театрның баш режиссеры Туфан Имаметдинов сәхнәләштерде.

Спектакльдә күбесенчә олы буын артистлар катнаша. Иң өлкәненә 76 яшь булса, иң яшь артистка – 20. Туфан Имаметдинов спектакльнең театрның олы буын артистларына рәхмәт йөзеннән куелганын әйтте:

– Театрны 90 яшенә кадәр кем җиткерде? Өлкән буын. Без аларга бик рәхмәтле. Алар – безнең тарих та, киләчәк тә.

Картлар йорты. Спектакльдә вакыйгалар әнә шул күңелне тетрәндергән, бәгырьләрне телгән урында бара. Күпме язмыш, күпме ялгышлар сыешкан биредә. Татар сәхнәсендә әлеге теманың күтәрелгәне бар иде инде. Әйтик, шул ук Тинчурин театрында гына да Аяз Гыйләҗевның «Ефәк баулы былбыл кош»ы төрле елларда сәхнәләштерелде. Тик күпме вакыт узмасын, бу тема һәрвакыт актуаль. Чөнки балалары булып та, ялгыз калган өлкәннәр саны арта, аларны сыендырган шундый йортлар да шактый бүген. Спектакльнең геройлары да гомер көзендә төрле сәбәпләр аркасында картлар йортына эләгә. Тик үзләренең мондагы тормышын һич кенә дә гомернең «соңгы тукталыш»ы дип кабул итмиләр. Ялгыз булсалар да, биредә аралашыр кешеләре бар аларның. Гадәти тормыш белән яшәүләрен дәвам иттерәләр, күңел ачалар, хәтта гаилә коралар. «Бу дөньяга сәхнә шаулатыр өчен яратылган» Мифтах (Сәлим Мифтахов), «ялгыз яшәр өчен яратылган» Гөлҗәннәт (Люция Галләмова), балаларына кирәк булмаган Фикус (Илгизәр Хәсәнов), бер тапкыр да кияүгә чыгып карамаган Кызбикә (Зөләйха Хәкимҗанова), картлар йортында кинәт кенә пәйда булган кара күзлекле Рәхимҗанның (Зөфәр Харисов) тормыш тарихлары гыйбрәтле. Кайчандыр үзләрен үстергән әниләрен (Ләлә Миңнуллина) шушы йортка балалары (Гүзәл Гайнуллина) китереп ташлаулары бигрәк тә тетрәндерә.

Татарстанның халык артисты Ләлә Миңнуллина үзенең герое Бүләкбану белән охшашлыклары күп булуын әйтте:

– Бүләкбану йомшак күңелле, бик бала җанлы, кешелекле. Шул яклары-быз охшаш. Тик тормыш күгендә ялгыз канат булып яшәү насыйп булган аңа. Ике кызын кочаклап, берүзе кала ул. Кызлары олы тормыш юлына аяк баскач, әниләрен картлар йортына илтергә мәҗбүр булалар. Кызларын өзелеп сагынып, бик күрәсе килсә дә, Бүләкбану гомеренең кышын ялгызлыкта каршы ала, – дип сөйләгән иде ул спектакльгә багышланган матбугат очрашуында. – Картлар йорты дип әйтергә тел дә әйләнми. Нинди генә авырлык булса да, геройларыбыз күңелләрен төшерми. Һәр нәрсәдән җиңеллек табарга тырышалар. Дөньяга килгәнсең икән, тормыш юлын авырлыкларга бирешмичә, матур итеп үтәргә кирәк бит инде. Алар да шулай.

Картлар йортындагы мохит тамашачыны төрле уйларга этәргәндер. Спектакльне залда утыручыларның күбесе – үзләре дә өлкән кешеләр тыныч кына карый алмады. Комедия булгач, көлгәне көлде, күз яшен сөртеп, моңсуланып утыручылар да булды. Чын тормышны чагылдыра бит. Әйе, картларның тормышлары әйбәт. Дәүләт тә аларны ташламый – сыеныр урыннары бар, тамаклары тук. Ләкин адәм баласына ул гына җитми икән шул. Якыннарының күңел җылысын тоеп яшәмәсә.

Ләйсән САФИНА

УКУЧЫ СҮЗЕ

КОТЛЫЙБЫЗ!

Тукай районы Мусабай-Завод урта мәктәбе коллективы 35 ел гомерен мәктәпне җитәкләүгә багышлаган, РСФСРның халык мәгарифе отличнигы, СССРның Мәгариф отличнигы, Татарстан Республикасының атказанган укытучысы **ИЛЬМАТОВ Аринат Гарипович**ны 85 яшьлек күркәм юбилее белән ихлас күңелдән тәбрик итә.

Аринат Гарипович – үзенең бөтен гомерен, бар көчен, йөрәк җылысын балаларга багышлаган хөрмәтле кешебез. Хәзерге көндә ул Арчада яши. Лаеклы ялда булса да, бездән еракта яшәсә дә, безнең белән һәрвакыт элемтәдә тора. Мәктәп, авыл, район тормышы белән даими кызыксына. Борчуларыбызга борчыла, уңышларыбызга сөенә. Үзенең төпле киңәшләре белән ярдәм итә.

Хөрмәтле Аринат Гарипович! Сезнең гомерегез намуслы хезмәттә үтте. Сез гомерегез буена сайлаган кыйблагызга, һөнәрегезгә тугры булып хезмәт куйдыгыз. Үз һөнәрегезне яратып, намуслы башкардыгыз, балаларны ихлас яраттыгыз, шуңа күрә укучылар һәм хезмәттәшләрегез арасында ихтирам яуладыгыз, ата-аналар, авыл халкы арасында да абруегыз зурдан булды.

Юбилеегыз белән котлап, күңелебез түреннән йөрткән иң якты хисләребезне җиткерәбез. Өстәлегез мул, җаныгыз тыныч, күңелегез күтәренке булсын. Тормыш иптәшегез Любовь Константиновна белән тигезлектә, саулыкта бәхетле, озын гомер кичерегез.

Тирән хөрмәт белән,
Мусабай-Завод урта мәктәбе коллективы

Алиция Юсупова / yusupova.pro

Гомер озын ул...

Кеше гомерләрен кыска, диләр,
Вакыт белән аны үлчәмә.
Еллар белән билгеләнми гомер,
Кылган эшләр белән үлчәнә.

Үткәннәрең балкып торса әгәр,
Гомер юлың озын тоелыр.
Бала-оныкларың алдында
Йөзең якты нурга коеныр.

Дөрес гамәлләрне алга куеп,
Эшкә кушсаң яшьлек аңыңны,
Үкенерлек булмас, горур басып,
Каршыларсың картлык таңыңны.

Дәртлеләргә якты юллар ачык,
Дөрес юлны сайлый бел генә.
Яшьлек көчен акыл җитәкләсә,
Шатлык, бәхет килер гел генә.

Тормыш юлы ничек үтелсә дә,
Тәкъдир-язмышларга сылтыйбыз.
Язмыш безне түгел, без язмышны
Ясаганны бик соң аңлыйбыз.

Кәүсәр ӘМИНОВ

ҺӨНӘР АШАРГА СОРАМЫЙ, ҮЗЕ АШАТА

Сайлаган һөнәр кешенең сәләтенә һәм мөмкинлегенә туры килергә тиеш. Үземә килгәндә, дүрт елдан артык лаеклы ялда булгач, яшьли сайлаган төп һөнәремнең актуальлеге югалды. Бүгенге көн мәнфәгатьләреннән чыгып, шәкерт булмый оста була алмассың, дигәндәй, өйдән генә эшли торган логист һөнәрен үзләштердем.

Балаларга да һәрвакыт әйтә килдем: үзегезне ашатырлык яхшы һөнәрегез, өстәвенә шөгылегез булсын. Кинәт кенә баеп китәргә биш кенә мөмкинлек бар, дип шаярта идем. Беренчесе – банк басу, икенчесе – берәр бай туганыңнан калган мөлкәткә ия булу, өченчесе – бай малаена кияүгә чыгу яки бай кызына өйләнү, дүртенчесе – бик саллы уку йортын тәмамлау һәм бишенчесе, безнең өчен иң кулай булганы – һөнәр иясе булу. Бай балалары ярлы эзеннән йөрми, аларның үз мохите. Безнең өчен иң кулае – хезмәт белән табу. Мул, шәп яшим, дисәң, чәчтарашмы, металл кисеп ябыштыручымы, плитә салучымы син, сайлаган һөнәреңне сәнгать дәрәҗәсенә күтәрергә кирәк була.

Шөгыльсез кеше юктыр ул. Кечкенәдән әниднән – тегәргә, чигәргә, әбидән бәйләргә өйрәндек. Юклык заманында үзебезгә дә, иребезгә дә, балаларга да тегеп кигердек. Бәйләү үрнәкләрен бер-беребездән күчереп ала идек. Бәйләгәндә әчке халәтең тигез сулый. Кулың белән тудырган матурлыкка соклана-соклана, онытылып эшлисең. Шәкерт эшне күп бозар, бер көн остадан узар, дигәннәр бит әле. Бәйләп бетердем дигәндә генә сүтеп аткан свитерлар, кулмәкләр ничә булды икән? Анныры, тәвәккәлләп, яңадан башлыйсың.

Без кече апа белән бер чорда бер уку йортында укыдык. Яшь арасы ике генә ел иде чөнки. Төрле факультетларда булсак та, беренче ике елны бергә тордык. Мин тегәм, апа кулмәкләрне ыргаклап бизи иде. Миңа шарф, берет, пирчәткәдән торган комплект кисп бирде. Безнең буын кызларының кул эше тота белмәгәне юктыр ул. Хәзергечә дуслар-туганнарны очрашуга кафега чакыру ят нәрсә иде безнең заманда. Аның мөмкинлеге дә булмады инде. Һәр хуҗабикә үзенең осталыгын чарлый. Хәзер аш-су рецептларын газета-журнал битләреннән карап, китапханәдә китап актарып, аерым дәфтәргә күчереп язарга һәм махсус китаплар сатып алырга да кирәкми бит. Интернетны ачасың да онлайн рецептлар эзлисең. Күпкә җиңел.

Унбиш ел дәвамында рухи яктан да, матди яктан да канәгатьлек биреп торган тагын бер шөгылем – тамада. Бу эшкә җырлый белүем, кешеләр белән аралаша алу осталыгым бик булышты миңа.

Бервакыт шулай Чаллы телевидениесендә эшләп йөргән мәлем. Көтмәгәндә бер ханым шалтырата: «Җитешә алмыйм, туйларым күп, бер кешегә тамада табып бирәм дигән идем, ризаласмассызмы?» – ди. Композитор Ренат абый Гобәйдуллин тәкъдим иткән икән. Әле ул вакытта, түләп, тамада чакырту гадәте яңа керен килә, бик белеп тә бетергән нәрсә түгел. Шулай да мин – Чаллы телевидениесенә килгәнче Виталий Агапов төркемендә җырчы булып эшләгән кеше. Бик күп тамашаларда, бәйгеләрдә, фестивальләрдә, спектакльләрдә катнашканым булды. Тәҗрибәле, туйдан-туйга йөргән баянчы да була, дигәч, ризалык бирдем. Әзерләнергә әллә ни вакыт юк. Булган шигырьләрне, уеннарны караштырдым да киттем туй үткәрергә. Җиде кат тирем чыкты, йөз агардым, йөз кызардым! Аллаһның рәхмәте төшсен теге баянчыга, ул кешенең исемен дә хәтерләмим хәзер. Шулай икәү ерып чыктык. Яхшы тамада буласың килсә, җор тел дә, хәтер дә, йолаларны белү дә, кунакларның, хуҗаларның кәефен тоемлау да кирәк икән. 15 ел чуплап-җыеп килгән һөнәремне төп эш урынымда җитәкче итеп билгеләгәч, килешми, дип ташладым. Вакытында юлдан борыла белергә кирәк.

Гомер үткән саен, мәнфәгатьләр, теләкләр башкага үзгәрә. Җан тырмашып җыйган һөнәрләрем бүген тарих киштәсендә. Калган гомеремне, егәрлегемне балаларым, оныкларым өчен саклыйсым килә. Спорт күнекмәләре сәламәтлегемне саклау өчен кирәк. Тормышымны хәрәкәттән башка күз алдына китерә алмыйм. Бәхетемә, ирем дә спорт сөючән, тырыш, максатчан кеше булып чыкты. Балаларыбызны яшьтән үзебез яраткан шөгыльләргә тарттык. Кыш керсәк, чаңгыда, тимераякта шуабыз, урман-паркларда йөгерәбез. Авыл җирендә яшәгән кешегә көн дә спорт, көн дә хәрәкәт диярсез. Көч сораган күнекмәләрдән кала сулыш гимнастикасы, йога, стречинг (сузылу) бар бит. Алары авыр эштән соң ял шикелле, соңгысын телевизор каршында да эшләп була. Эшлисе килмәгән кеше йөз сәбәп табачак. Спорт ярдәме белән балаларыма авырлык китермичә, олыгайган көнемдә дә җиңел гәүдәле, җыйнак, үз көчемдә, үз аягымда, ачык акыллы буласым килә.

Миңа әчке дөньямның да, тышкы дөньямның да тәңгәл булуы хак. Бик кызыклы шөгылем бар әле тагын. Тәртип яратам! Киштәндә һәр нәрсә урынында торса, башыңда да тәртип, димәк. Өйдәге һәр артык әйбер энергияне алып тора. Киракмәгән әйбер ташланыра, бүләк ителергә, сатылырга тиеш. Һәм инде, һичшиксез, гомеремне мәгънәле иткән, күңелне талпындырган, якты көнемне, зәңгәр кичемне тулыландырып җибәргән шөгылем – шигырь язу. Йөрәгемә шигырь каккада, тирә-ягым нурланып китә минем!

Фирдәүсә БИКМӘТОВА. Казан

ГАИЛӘ БӘХЕТЕ ТУРЫНДА ФӘЛСӘФӘ

Чынбарлык шул: үзеңнән башка сине беркем дә бәхетле итә алмый. Ирең я хатыныңның, әниең я балаларыңның тормышыңны ялтыравыклы кәгазьгә төрелгән тәмле конфит итеп ясаулары көтү ул – чынга ашмас бер фантазия генә. Нык якын кешеләрең да синең эчке рухи дөньяңны канәгатьләндереп бетерә алмый. Шуңа күрә өйләнешеп күпмедер вакыт узганнан соң, бербөтен булып яисә бертөрле фикер йөртеп, бер ритмда сулыш алып яшәргә кирәк, дигән фикердән яшьләрнең күңелләре кайта. Без ничек кенә теләсәк тә, икенче кешене тулысынча бәхетле итә алмыйбыз. Әйе, аңа бер вагон бүләк тә ала алабыз, никадәр эшләрендә дә ярдәм итәбез, ләкин бербөтен булып бетә алмыйбыз. Билгеле бер вакыттан соң барыбер ир белән хатынның мәнфәгатьләре, кызыксыну өлкәләре, бер-берсенекенә туры килмәгән хоббилар, мәдәният, мода, сәясәткә, хәтта ашау әйберләренә дә карашлары төрле булуы ачыклана. Гаиләдәге һәр кешенең шәхси бәхете, яраткан шөгыле, үз фикердәшләреннән торган компаниясе булырга тиеш.

«Бербөтен бәхет» төшенчәсен дөрес аңламау аркасында ир яки хатынның берсе канәгатьсезлек белдерә башлый. Янәсе, аның ире (хатыны) гаиләдән читләшә, вакытын читтәге дуслары белән үткәрә, аңа тиешле игътибар бирми, дуслары начар, тегеләр яки бу шөгыль белән вакытын юкка үткәрә әрәм итә... Уртак бәхетне болай эзләүнең нәтиҗәсе әйбәт бетми. Ир белән хатынның бер-берсенә үпкәсе торган саен арта. «Ул миңа тиеш» дигән фикердә яшәгән гаилә иртәме-соңмы таркала. Исегездә тотыгыз: беркем беркемгә тиеш түгел. Ир яисә хатынга сезнең тормышны җайлырак, уңайлырак итү инструменты итеп карамагыз.

Мин хәзер аңлыйм: асылда, безнең һәркайсыбызның үз тормышы һәм ул – бердәнбер әһәмиятле юлыбыз. Ә ир яки хатын сезнең икенче яртыгыз түгел. Ул да – юлчы, тик сезнең белән янәшә бара торган юлчы. Аның да үз инанулары, үз ышанулары, бу дөньяга карата үз уй-фикерләре бар. Аларга хөрмәт белән карарга кирәк. Ир – хатын бербөтен түгел, а аерым-аерым кешеләр. Яшьләр моны аңласыннар, җаваплылыктан качып, гаилә йөген бер-берсенә атмасыннар иде. Еш кына шулай да була. Бер-берегезне үзегезгә уңайлы итеп үзгәртергә тырышмагыз, киресенчә, уртак тормышта иркегез яки хатыныгызның күңелен, рухын канәгатьләндерердәй юллар эзләгез. Шуннан соң гына бергә яшәгән кешегезнең җаны тынычланыр. Мөнәсәбәтләрне яңабаштан карасагыз, инде тормыш сукмакларыннан бергә атларга ашкынып торган бәхетле кешеләр булырсыз.

Хәбир ХАНОВ

Скрипка

Кайбакыт интернет челтәрләрендә «Север» дигән тәмәке тартмасы сурәте күренгәли. Күңелдә кабат хатирәләр яңара... «Север» тәмәкесен тарта иде әтием. Бары тик тышта, ишегалдында гына. Мин аның өйдә тәмәке тартканын беркайчан да күрмәдем. Әле дә шунда, иске лапасыбызның ургасында торган юан биек утын «пүлине» өстендә аягын тез өстенә куеп, үзенә генә билгеле уйларын уйлап утыра сыман...

Әтиемнең скрипкада уйнаганын мин бер генә тапкыр күрдем. Үз скрипкасы юк иде, шуңадыр инде. 1969 елның көзендә Арча районы скрипкачыларыннан ансамбль төзеп, чыгышларга әзерләнә башладылар. Әтиемә дә скрипка биргәннәр иде. Аның 60 яшьлек юбилей көннәре килеп җиткәндә скрипка бездә иде.

Баштә әтиемне клубта авыл үзешчәннәре оештырган кичәдә котладылар. Төрле елларда башлангыч мәктәптә әтием укыткан укучылары килгән иде. Барысы да диярлек хатирәләр белән уртаклашты. Гаҗәп хәл булды ул. Шулкадәр күп рәхмәт сүзләре яңгырады ул кичне. Суз әйтүчеләрнең һәрберсе диярлек сөйли башлый да елый... Тамашачылар елый. Без елыйбыз... Андый җылы, «елак» кичәне мин башка бервакытта да күрмәдем...

Кичә тәмамлангач, алдан чакырылган кунаклар безнең өйгә, мәҗлескә юнәлде. Кунаклар өстәл янында матур гына сөйләшкәләп, без, балалар, әниебезгә булышабыз. Менә бервакыт өйалдына әтием килеп чыкты. Кулында – скрипка. Кунакларга уйнап күрсәтәсе иткән. Скрипкасын җилкәсенә куйды да кыллары беркетелгән винтларны бора-бора көйләде. Скрипкасын «настраивать» итте. Аннан соң түр өйгә – мәҗлескә килучеләр янына кереп, скрипкада уйнады... Кунаклар тын да алмый тыңладылар аны. Арчада чыгыш ясаганын тыңларга насыйп булмады... Бер айдан, ноябрьдә әтиебез көтмәгәндә арабыздан китте... Бик күп нәрсә турында сорашылмый, сөйләшенми калды. Бигрәк тә сугыш еллары турында сөйләргә яратмый иде...

Фәрдия СӘФӘРГАЛИЕВА

Авылча яшәп ятыш

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Бу рубрика сезнең күңелләргә бигрәк тә хуш килер, мөгаен. Сез ниләр майтарып ятасыз? Нинди яңалыклар бар? Язгыз әле безгә. Башкалар белән дә уртаклашыйк.

«МАРАТКА РӘХМӘТ ӘЙТ ӘЛЕ»

Җай чыкканда, йомыш төшкәндә район үзәгенә барырга яратам. Таныш-белеш күп очрый. Мин таныганнары, танымаганнары, онытканнары да исемләп эндәшеп, хәл-әхвәл белешеп китә. Район газетасы редакциясендә егерме елдан артык эшләгәнгә, шөкер, әле дә онытмыйлар. Бигрәк тә өлкән буын, аларның күбесе «Ватаным Татарстан»ны укый, инде таги егерме елга якын анда эшләвемне белә, минем язмаларым турында да, башкаларның турында да фикерләрен әйтергә яраталар. Ашыкма, иренмә, тыңла гына...

Шушы көннәрдә тагын Балтачка барырга туры килде. Юл уңае дип базарга сугылмакчы идем, каршыма килүче 65–70 яшьләрдәге бер ханым туктатты.

– Гөлсинә сеңлем, очравың әйбәт булды әле, ничек кенә өегезгә шалтыратыйм дип йөри идем. Мин сезнең газетаны «Социалистик Татарстан» чагыннан укыйм. Әле дә килгәнен көтеп алам. Бөтен журналистлар да бик әйбәт яза. Әмма Маратның – Марат Кәбировның язганнарын аеруча яратып укыйм. Бигрәкләр дә булдырып яза бит ул! Без уйлап йөргән әйберләрне, безнең күңелдәгеләрне шулкадәр матур итеп, әллә нинди фәлсәфи мәгънәләр салып әйтә дә бирә инде менә... Карале, мин дә күпме шуны уйлап йөрдем бит дисең. Уйлавын уйлыйбыз да, тик Марат кебек итеп әйтә, яза белмибез шул.

– Шуңа күрә язучы бит инде ул. Шәп язучы, – дим.

– Шәп язучы шул, – дип килешә апаем. – Күрсәң, рәхмәт әйт әле шул Маратка. Балтачтан Сания апаңнан диген. Синнән гел шундый язмалар көтеп торалар диген.

– Ярар, – дип саубуллаштым да уйга калдым. Әле кайчан Казанга барам, әле кайчан Маратны күрәм... Өстемдә әманәт булып йөрмәсен дип, Сания апаның рәхмәтен газета аша җиткерергә булдым. Кабул итеп ал, Марат!

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

ЛИЛИЯ ГӨЛЛӘРЕ

Шулай бервакыт шигырьләр укыганда, Лилия Фәттахова иҗатына тап булдым. Кызыклы тоелды. Мәсәлләргә таянып эш итә. Кыска, тар, төгәл әсәрләре дә юк түгел. Кызыксыну үсте. Танышканнан-таныша барам. Тезмәләрдә характер үзенчәлеге ярылып ята. Көзге тайгак көн кебек. Ләкин матур. Табигать белән үрелеп килә. Күрәсең, шагыйрә табигатьне ярата. Йөри, күзәтә. Каләмен чарлый. Бер кабына, бер сүнә... тына.

Кызыклы шәхес булып чыкты бит әле ул.

Кулымда «Ишет мине» китабы. Укыйм. Күңелгә ниндидер фикерләр, уйлар килә – авторга карата тойгылар көчле. Сынаучан, кискен, ничек кабынса, шул килеш пыскырга да мөмкин кебек. Үзем белән охшаш характерлы. Сыйфатлары шигъри тәлгәшләрендә сизелә сыман. Мәсәлән, «Болай гына уфтану» шигыре. Сүтеп җыйганда, шактый гына үзенчәлекле характер билгеләре ачыла, әмма матур афоризмнар: «Күңел көзгесе тоныграк», «Өзелеп иткән чәчәк», «Яралы кошчык». Афоризмнан соң көчле фикер тезмәсе килә: «Тупаслана, тутык баса, Бурсый башлый ич күңел». Тукта, ә бу нәрсә? «Без андый түгел идек, Без нич андый түгел». Акланумы бу, тормыш кыйнавына охшаш элемент. Ышану билгесеме? Ышанычы югалуга күбрәк бара кебек. «Балачакның ал күзлеге кайчан салынды икән?» Дәлиле дә бар: «Күңел бакчасына кайчан кырау кагылды икән?»

Менә кайда ул бәя, төгәллек. Бөтен бер характер ачылышы.

Тарих укытучысы буларак, үсеш ике баскычта. Хәер, әдәбият тарих белән аерылгысыз. Бу Лилиянең иҗатында да ачык чагыла: «Тарихны кем яза», – ди. Тагын менә игътибар белән карагыз: «Халык бит ул – Кемдер өйгән бер зур кибән».

Җавапмы? Оста. Бик оста. Тукталып калмый, юлын дәвам итә: «Кирәк чакта туендыра... Кирәк икән, шырпы гына тәртә». Чыннан да, карагыз әле метафоризм: «акыллыбаш», «Дөрләп янып китә». Үзе әйткәндәй, «Сиптем-җыям уйларымны, сүттем-җыям». Миңа ошый. Сез ничек уйлыйсыздыр, белмим. Ә антонимнарны ничек тезә: көйсез – көйле, көчле – көчсез, синонимы – башсыз, көчсез... Капма-каршылык ничек сарылган шигырьгә: асылы тыйнак, чуп сара, чөнки ул – «хуҗа». Ул моны тарсынмыйча, тайпылмыйча әйтә:

«Мин – иясе уйларымның,
Мин – хуҗасы.
Ничек сызам сызымымны –
Шул буласы».

Ишеттем, Лилия. Бик матур, аһәңле иҗат.

Сәрия НУРИЕВА

БЕЗ – КАЛЕНДАРЬЛЫ ХАЛЫК

Татар халкы – гомер-гомергә китаплы, укымышлы халык. Ул мәгълүматны таратуның нинди генә формаларын кулланмаган. Шуларның берсе – календарьлар. Каюм Насыйри заманыннан ук килгән бу басмалар көннәр, айлар язылган гади нәрсә түгел, анда нәкъ шул көнгә туры килгән төрледән-төрле мәгълүмат бирелә. Инде хәзер календарьларның ниндиләре генә чыкмый.

Алар арасыннан миңа Фәния Хуҗахмәт чыгарган «Татар мөселман календаре» бик ошый. Ул инде 30 ел нәшер ителә һәм мин аларны беренче санынннан ук туплап барырга тырышам. Ул миңа ни өчен кадерле? Монда дини мәгълүмат та, гавами мәгълүмат та шактый. Дини мәгълүматтан һәр көнне кирәкле намаз вакытлары, догалар, хәдисләр мулдан бирелсә, гавами мәгълүматтан шәхесләр, аларның иҗатлары урын алган. Әйтик, язучы Марсель Галиевның дингә карашын укып сокланган идем.

Ул миңа атаклы журналист Шәех Зәбиров эшенең дәвамы булуы белән дә кадерле. Аңа озын гомер, бай эчтәлек телим.

Клара ТАҖИЕВА, музыка белгече

Бергә җыелганда

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

Киңәш-табыш

Тимәсен салкын

Үз гомерендә бер тапкыр булса да салкын тиеп авырмаган кеше юктыр. Көз көне салкын тию авырулары исә тагын да ешая. Алардан ничек сакланырга? Йөткерү-төчкерү сезонында авыруга бирешмәүнең гап-гади ысулларын тәкъдим итәбез.

Аяк һәм борын – җылыда

Салкын тидермәс өчен иң мөһиме – аякларны һәрвакыт җылыда һәм корыда тоту. Тик ул гына җитми әле. Табиблар борынны да җылыда тотарга киңәш итә. Борыныгыз туңса, шарф белән каплагыз, җылы чәй яисә каһвәнең парын сулагыз. Һава торышының ничек булуына карап киенеп йөрү дә бик мөһим.

Иярмәсен өчен чир

Халык күп җыелган урыннарга (җәмәгать транспорты, кинотеатрлар, хастаханәләр) барудан тыелып торыгыз. Чөнки анда салкын тию яисә грипп йоктыру куркынычы кискен арта. Вирус таратучылар белән аралашмаска тырышыгыз. Гигиена кагыйдәләрен үтәү дә мәҗбүри. Кулларны ешрак сабын белән юарга кирәк.

Кул бирешеп күрешмә

Йогышлы авырулар сезонында болай исәнләшүләрне сирәгәйтергә кирәк. «Кул бирешү ныграк һәм озаграк булган саен, кешеләр бер-берсенә микробларны күбрәк тапшыра», – ди Британиядәге Аберистуит университетының биохимия профессоры Дэвид Витворт.

Су гына, димә

Суның файдасы турында табиблар да, спорт тренерлары да, диетологлар да сөйли. Авырулар сезонында сыеклыкны аеруча күп эчәргә кирәк. Көненә 2 литр чамасы су эчегез. Ул организмнан зарарлы матдәләрне чыгарырга һәм аны дымга туендырырга булыша.

Иммунитетны ныгытабыз

Организмның күп кенә функцияләре дөрес эшләсен өчен, Д витамины кирәк. Ул җитмәсә, организмда иммун системасын тиешле дәрәҗәдә тотучы матдәләр азрак эшләп чыгарыла. Шуның аркасында вирус эләктерү ихтималы өч тапкыр арта. Д витаминына иң бай ризыклар: балык мае, бавыр, йомырка, сөт ризыклары, гөмбә, атланмай, ит.

Спорт кирәк, әмма...

Спорт белән артык мавыксаң, организмда стресс гормоннары күпләп эшләп чыгарыла башлый икән. Организмга көч килерлек физик активлыктан тыелып торыгыз. Җәяү йөрү, чаңгыда, тимераякта шуу, киерелеп-сузылып, салмак күнегүләр ясау файдалырак булыр.

ИСЕҢДӘ ТОТ!

! Кыш һәм яз башында елгалардагы юка бозга чыгарга ярамый.

! Өстенә кар яткан боз өстендә дә уйнарга ярамый. Ник дигәндә, кар астындагы боз ярылган, анда чокыр хасил булган булырга мөмкин.

! Онытма: яз башында боз – тавышсыз гына, кыш башында ярылып, чатнап ватыла.

! Ярылган зур боз кисәкләре өстендә йөрү дә куркыныч. Алар бик тиз ватыла. Моннан тыш боз кисәкләре, судагы әйберләргә бәрелеп, әйләнеп капланырга да мөмкин.

! Бозлы суда батучы кешене күрсәң, тиз арада өлкәннәрне чакыр, коткару хезмәтенә шалтырат. Ярдәм көткәндә бозлы суда батучыга бау, шарф яки озын ботак ыргыт.

Сәхифәне Ләйсән САФИНА әзерләде

ХӘБИБӘ ГЫЙНИЯТУЛЛИНА:

«ТОРТ ПЕШЕРЕП, БАЕП БУЛА»

Бүгенге кунагыбыз – тәмле итеп тортлар пешерүче Кайбыч кызы Хәбибә Гыйниятуллина. 11 яшендә беренче тортын пешереп караган кыз бүген ныклап торып кондитерлык эше белән шөгыльләнә. Яшь кондитер белән телеңне йотарлык тортлар пешерү серләренә төшендек.

:: Хәбибә, беренче тортыңны ничә яшеңдә пешердең?

– Беренче тортымны унбер яшьтә пешердем. Төрле кулинар телешоулар карап, кызыксынып киттем. Миңа рецептларны әнинең апасы бирде. Үзе дә еш пешергәч, миңа бөтенесен әйтеп, яздыртып бара иде. Нәрсәдер килеп чыкмаса, аннан ярдәм сорыйм. Татлы әйбернең дә үз җае бар. Аз гына читкә тайпылдыңмы, нәтиҗә сөендерерлек булмый.

:: Кулларыңнан уңгансың, социаль челтәрләрдәге фикерләргә карасак, заказ бирүчеләрең дә җитәрлек бугай.

– Әйе, социаль челтәрләр аша заказ бирүчеләр шактый. Бер алган кеше кабат-кабат килгәч, үсенеп китәсең бит ул. Мин дә үсенеп китеп, махсус сәхифәмне булдырдым. Кешеләргә ризыкларым бик ошый.

:: Ә күпме вакыт кирәк соң торт пешерү өчен? Бу эштә иң авыры нәрсә?

– Вакыт та, түземлек тә, сабырлык та бик кирәк. Иң күбе дигәндә – алты сәгать. Пешерү процессында минем өчен иң авыры һәм шул ук вакытта иң кызыгы да – тортның дизайнын уйлау. Тортны бизәү чын иҗат эшенә тиң. Монда барлык фантазияне эшкә җигәргә кирәк. Дизайн аша мин үзенчәлегемне күрсәтергә тырышам.

:: Хәзер инде бәясен дә беләсе килә.

– Тортның 1 килограммы 1500 сум тора.

:: Торт пешереп, баеп буламы?

– Әйе, торт пешереп, күп акча эшләп була. Әгәр даими рәвештә моның белән шөгыльләнсәң, заказларың күп булса. Бәйрәмнәр – кондитерлар өчен аеруча табышлы чор.

Кунагыбыз турында белешмә

- Хәбибәгә – 15 яшь.
- Олы Кайбыч урта гомуми белем бирү мәктәбе – цифрлы һәм гуманитар профильле белем бирү үзәгенең 9 нчы сыйныфында укый.
- Гыйниятуллиннар гаиләсендә җиде бала. Хәбибә – өченчесе.
- Киләчәктә үзенең кондитерлык фабрикасын ачарга хыяллана.

:: Авызда эреп китәрлек торт пешерү сере нидә?

– Карап торуга торт пешерүнең бер кыенлыгы да юк кебек. Әмма һәр эшнең үз нечкәлекләре бар. Беренче чиратта барлык этапларны төгәл үтәү таләп ителә. Монда бик уйлап эш итәргә кирәк. Продуктларның нинди күләмдә кулланылуын һәрчак истә тотарга кирәк. Пешергәндә температура режимы да зур әһәмияткә ия. Бисквит камыры белән бик төгәл эш итү сорала. Һәм, әлбәттә, тәмле торт килеп чыксын өчен, аңа үз мәхәббәтеңне салырга кирәк.

:: Хәбибә, тагын нинләр белән шөгыльләнәсең?

– Матур фотосурәтләр төшерәм, видеолар ясыйм. Укырга да яратам, бөтен чирекне «5ле»ләргә генә тәмамлыйм.

:: Ә киләчәктә үзеңне нинди һөнәр иясе итеп күрәсең?

– Үземнең кечкенә генә булса да кондитерлык фабрикамны ачасым килә. 9 нчы сыйныфтан соң эшмәкәрлек факультетына укырга керергә уйлыйм.

Әңгәмәдәш – Ләйсән САФИНА

Белеп тор!

КАНИКУЛДА НИШЛӘРГӘ?

Көзге каникулны кызыклы һәм файдалы итеп үткәрергә телисезме? Ул чакта без сезгә әзерләгән чаралар белән танышырга ашыгыгыз.

Шәрык клубы

Галиәсгар Камал театрының Шәрык клубы көзге каникул вакытында балаларны «Кечтүк» театраль мастер-классларына чакыра. Балалар өчен мавыктыргыч мастер-класс, Г.Камал театры буенча сәяхәт, артистлар белән очрашулар, уенлы лекция һәм башка бик күп төрле чаралар көтә. Театраль мастер-класс 30 октябрьдән 3 ноябрьгә кадәр үтәчәк. Остаханә татар телендә уза. Актерлык осталыгын өйрәнеп, чын сәхнә йолдызы буласың килсә, остаханәгә рәхим ит.

Казан Кремле

Казан Кремле музейларында төрле яшьтәге укучылар өчен интерактив программалар һәм белем бирү дәресләре уза.

«Эрмитаж-Казан» үзәге

«Бәхет батырларга елмая, яки Уңышлы уку серләре» мәктәп программасы кысасында төрле яшьтәге балалар өчен интерактив дәресләр һәм экскурсияләр үткәреләчәк. Балаларны борынгы тарихка интерактив дәресләр көтә.

Мәктәп төркемнәре игътибарына

- «Македонский эзләре буйлап, яки Җир чигенә сәяхәт» башлангыч мәктәп өчен, 6+
- «Македонский тарихы, яки 60 минут эчендә ничек бөек булырга» урта мәктәп өчен, 10+
- Төрле яшьтәге балалар өчен күргәзмә буенча экскурсия

Әти-әниләр белән килүчеләргә

- Балалар һәм ата-аналар өчен күргәзмә буенча уен картасы
- Казан Кремле буенча «Хәзинә эзләү» уен-квесты

baytik-kazan.ru

Инклюзив программа

«Казан Кремле белән беренче танышуым». Экскурсия, 7+

Иң кечкенә кунакларны борынгы ныгытма буйлап сәяхәткә чакыралар. Анда сез Казан Кремле тарихы, аның геройлары һәм риваятьләре белән танышачаксыз. Сезгә сәяхәт барышында интерактив карта булышачак.

Программалар һәм экскурсияләрне алдан язылу буенча теләсә кайсы уңайлы вакытта үткәрергә мөмкин. Билетларны «Пушкин картасы» буенча да сатып алып була.

«Кремль аһәңе» сәнгать проекты

Билгеле объектларда: Спас манарасында, Гавами урыннар ишегалдында, Благовещение соборы артындагы җирлектә, шулай ук Казан Кремле диварларында инсталляцияләр күрсәтеләчәк. Барлык мәйданчыкларга керү ирекле.

Лагерьлар барын онытма!

Көзге ялларда күп мәктәпләрдә укучылар өчен лагерьлар оештырыла. Каникулны күңелле, мавыктыргыч һәм сәламәтлек өчен файдалы итеп үткәрергә менә дигән мөмкинлек бу. Нәрсә эшләргә, көнне ничек уздыру турында уйланасы юк. Барысы да инде әзер. Димәк, алда сине мавыктыргыч сәяхәт, онытылмаслык каникул көтә!

Безгә язалар

Әмирханова Нармин мин –
Актаныш авылыннан.
Бакча эшен яратканга,
Күп уңыш алдым көздән.
Кабак, кишер, чөгендерен –
Барысын да мин үстердем.
Суык көннәр җитә диеп,
Аларны җыеп кердем.

Тест

Моңлы сандугач

Иртәгә, 1 ноябрь көнне, татар халкының беренче профессиональ хатын-кыз композиторы, талантлы актриса һәм җырчы Сара Садыйкованың тууына – 117 ел. Данлыклы шәхес турында ниләр беләсез? Әйдәгез, шуны тикшереп карыйк.

1 Сара Гариф кызы Садыйкова кайсы шәһәрдә туган?
а) Мәскәү;
б) Казан;
в) Уфа;
г) Чаллы.

2 Сара Садыйкова иҗат иткән җырлар?
а) «Дөнья матур, дөнья киң»;
б) «Җидегән чишмә»;
в) «Казан кичләре»;
г) барысы да.

3 Сара Садыйкованың иҗат язмышына зур йогынты ясаган очрашу кайсы композиторлар белән була?
а) Заһид Хәбибуллин;
б) Нәҗип Җиһанов;
в) Солтан Габәши;
г) Салих Сәйдәшев.

4 Сара Садыйкова югары музыкаль белемне кайда ала?
а) СССР зур театрының опера студиясендә;
б) Мәскәү филармония училищесында;
в) Мәскәү консерваториясе каршындагы опера студиясендә;
г) И.В. Әүхәдиев исемендәге Казан музыка көллиятендә.

5 Сара Садыйкованың кызы кем?
а) Гөлшат Зәйнашева;
б) Әлфия Айдарская;
в) Флюра Сөләйманова;
г) Сажидә Сөләйманова.

Җаваплар: 1.б); 2.г); 3.в,г); 4.а); 5.б).

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5146 данә
Гомуми тираж – 13580 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 347

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – **газета килмәсә яки соңарып килсә**

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+